# Татарча мәкальләр һәм әйтемнәр

*татарские пословицы и поговорки*

автор
Р. Н. Ахмадишина

Регина Ахмадишина

# Татарские пословицы и поговорки

«Автор»
2022

**Ахмадишина Р. Н.**

Татарские пословицы и поговорки / Р. Н. Ахмадишина — «Автор», 2022

Татарские пословицы и поговорки составляют неотъемлемую часть народного языка и культуры. Они заключают в себе историю и опыт, традиции и характер народа. Пословицы не только обогащают наш язык, но делают его уникальным и неповторимым. В сборнике собраны наиболее часто встречающиеся выражения. Каждая пословица и поговорка сопровождается переводом на русский язык.

© Ахмадишина Р. Н., 2022
© Автор, 2022

# Содержание


Моральные качества, характер, привычки 5
Любовь 9
Здоровье 11
Деньги 12
Строение тела человека 14
Семья и родственные отношения 15
Язык 18
Животный мир 21
Труд 26
Человеческие отношения 28
Дети 35
Ум 37
Еда 41
Природа 43
Время 50
Вера 53
Драгоценные металлы, камни 54
Родина 57
Смерть 60
Добро, зло 62
Одиночество 63
Время года 65
День, ночь 68
Дорога 70
Жизненные ситуации 71
Гостеприимство 89

# Регина Ахмадишина
# Татарские пословицы и поговорки

## Моральные качества, характер, привычки

Алланың каш текәсе
Пуп земли

Авырткан башка тимер таяк
На больную голову действует лишь железная палка

Авызыңа бал да май!
Твоими устами да мед пить

Аңа диңгез тубыктан
Ему море по колено

Аллага да юк, муллага да юк
Ни богу, ни мулле

Авыр таш, кузгатсаң, җиңеләя.
Камень тяжел пока на месте лежит, сдвинешь – легче станет

Авыз эчендә ботка пешерә
Варит кашу во рту

Тәвәккәл таш ярыр.
Смелый города берёт

Каты кешедән кар сорама
Зимой снега не выпросишь

Күңел күзе күрмәгәч, маңгай күзе ботак тишеге
Рассеянный и верблюда не заметит

Мактанчыкныңарты ачык
У хвастуна спина открыта

Көчле яман түгел – үчле яман
Опасен не тот, кто силен, а тот, кто мстителен

Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс
Старательный не пропадёт, ленивый и света белого не увидит

Йокы капчыгы, йокы чүлмәге
Сонная тетеря
Иргә да ярый, мирга да ярый

И для мужа хороша, и для мира хороша

Иренгән ике эшләр (атлар)
Ленивый сделает (шагнёт) дважды

Батыр бер үлгәнче, куркак мең үләр
Пока смелый погибнет один раз, трус успеет тысячу

Батыр ярасыз булмый
Храбрец без ран не бывает

Батыр яуда беленер, телчән дауда беленер
Храбрый познается в битве, болтун – в раздоре

Батыр яуда сынала
Храбрый познается в битве

Батыр үзе өчен туар, кеше өчен үләр
Храбрый родится для себя, а умрет за другого

Батырлыкта – матурлык
В храбрости – красота

Авыр тормыш тилмертә, җиңел тормыш тилертә.
Тяжелая жизнь закаляет, лёгкая – отупляет

Агылый белән тагылый
Не разлей вода (два неразлучника)

Азамат ирнең баласы, өстенә яу килсә дә моңаймас.
Смелого молодца ничто не спугнет

Акыллы атын мактар, юләр хатынын мактар, шыр тиле үзен мактар
Мудрый хвалит свою лошадь, глупый – свою жену, дурак – себя

Алпарына күрә толпары
Каков рыцарь – таков и конь

Алты-биш / Алты–биш Сафи
О человеке с придурью / придурковатый

Алып анадан туар, аргамак биядән туар
Богатырь рождается от матери, скакун – от кобылы

Ардаксыз кайда да артык
Жалкий – лишний везде

Ардаксызның аркасы да туза
У беспомощного изнашивается даже спина

Астан кереп, өстән чыккан
Не в дверь, так в окно

Астыннан кисеп, өстеннән ямый
Отрезая снизу, сверху пришивает

Асыл кеше алтын дип үлмәс, халкым дип үләр
Настоящий человек отдаст душу не за золото, а за народ

Һәркемнең бармагы үзенә таба кәкре
Пальцы каждого скрючены в свою сторону

Егылганны кем дөмбәсләми
Лишь ленивый не колотит упавшего

Юха елан
Змея подколодная

Югары булып күктә юк, түбән булып җирдә юк
На небо его нет, а на землю путь не близок

Югары менгәч, түбән карама
Взобравшись высоко – вниз не смотри

Югары ятсаң – җил алыр, түбән ятсаң – сил алыр
Ляжешь высоко – продует, ляжешь низко – сель заберёт
Югарыга карап фикер ит, түбәнгә карап шөкер ит
Глядя наверх – задумывайся, глядя вниз – будь благодарен

Югарыга карап үрнәк ал, түбәнгә карап гыйбрәт ал
Глядя наверх бери пример, глядя вниз – извлекай урок

Юан сузылганчы, нечкә өзелер
Пока тучный подвинется, худой – надорвется

Юаштан юан чыга
Из доброго добротный получается

Ыспай ялтырар, эчтән калтырар
Снаружи блестит, а внутри дрожит

Чәчәк кормы түгел, а формы
Ценность цветка не в содержании, а форме

Чыкмаган җанда өмет бар
В теле с душой есть надежда

Холкы начардан дуслар кача

От человека с дурным нравом бегут друзья

Тышы гөл кебек, эче көл кебек
Снаружи красота, внутри чернота

Тышы ефәк, эче кибәк
Снаружи – шелк, а внутри – мякина

Тышын күреп, эченнән бизмә
Не суди по внешности

Тын сазда – корт күп була
В тихом омуте черти водятся

Сабыр төбе сары алтын
Основа терпения соткана из золота

Сакаллы сабый
Бородатая детина

Суйган да каплаган
Как две капли воды

Сантыйга акыл кирәкми
Дураку и ум не пригодится

Нәрсә белән нәрсә арасы – җир белән күк арасы
Разница между ними как между небом и землей

Кешене беләсең килсә, холкына кара
Хочешь узнать человека, смотри на нрав

Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт
Изучай характер человека, но работай над своим

Көчле күт тегермән тарта
Сильный стан мельницу перевернет

Кәкре белән бөкере – икесе дә бер
Кривой – косой – все одно

Кәкренең шәүләсе дә кәкре
Укривого и тень кривая

Кыланышы кырга сыймый
Поведение не входит ни в какие рамки

# Любовь

Аңа карап кояш тотылмас
Свет клином не сошёлся

Гашыйк булган күзсездер
Любовь слепа

Аем кыздан ай бизәр, яман кыздан яу бизәр
От красивой девушки луна отвертнётся, от злой девушки – все/многие

Өйләнмәгән егеткә ни кылса да килешә
Холостому парню всё идёт

Сөймәгәнгә сөйкәлмә
Не увивайся около того, кто не любит

Көнче көн күрмәс
Ревнивец света белого не видит

Киң булсаң, ким булмыйсың
Полнота не неполноценность

Йокы ястык сорамый, мәхаббәт яшь сорамый
Сон не спрашивает о лежанке, любовь – о возрасте/Любви все возрасты покорны

Иш – ишен табар, су – тишеген табар
Половинка найдет совю пару, вода – найдет отверстие

Бәхете яман егеткә бидәү хатын тап булыр
Счастливому злому парню – не родящая женщина будет находкой

Үткән-беткән, җилгә очкан
Вода утекла, ветер рессеял

Үч төбендә генә йөртү
Носить на руках

Үзеңнеке – үзәктә
Всякий свое любит

Ялгыз башка кайда да бер: таң ата да кич була
Одинокому все равно: с рассветом наступает закат

Яратуга тарыма, тарысаң арыма
Не держись за любовь, а коли держишься – не уставай

Ярканат яратмый дип, кояш чыкмый тормый

Говоря, что летучая мышь не любит, солнце без восхода не остается

Юлга чыксаң иптәшең узеңнән да яхшы булсын
Спутник, выбранный для дальней дороги, должен быть лучше тебя

Чиләгена (күнәгенә) күрә капкачы
К каждому горшку своя крышка

Туйга барсаң туеп бар
Идёшь на свадьбу – приходи сытым

Туйда тукмак та бии
На свадьбе даже колотушка танцует

Көнчелек гомерне кыскарта
Ревность делает жизнь короче

# Здоровье

Авыруың булса булсын, бурычың булмасын
Болезнь пусть будет, лишь бы долгов не было

Шыгырдаган агач тиз сынмый
Скрипучее дерево быстро не сломится

Байлык – бер айлык, саулык – гомерлек
Богатство на месяц, здоровье – на всю жизнь

Шуны күрдем исә, чирем яңара башлый
При виде этого болезнь оживает

Чирле бәрәнгә итәк җиле дә җитә кала
Этому слабому ягненку достаточно дуновения ветра

Чирен яшерган – үлгән
Скрывший болезнь – обречен на погибель

Чыкмаган җанда өмет бар
На живого надежда еще есть

Чир китә – гадәт кала
Боезнь уходит, а привычка остается

Чирен яшергән – үлгән, бурычын яшергән – бөлгән
Скрывший болезнь – погиб, скрывший долг – разорился

Саулык – иң зур байлык
Здоровье – самое большое богатство

Кояшның кадере баегачбеленә, сәламәтлекнең кадере – авыргач
Ценность солнца понимается с закатом, а ценность здоровья познаётся в болезни

# Деньги

Акча башны ашый
Деньги губят

Акчаның күзе юк
У денег нет глаз

Акча бездә бер букча
Денег куры не клюют

Акчалының кулы уйный, акчасызның күзе уйный
У денежного играют руки, у безденежного – глаза

Ярлы башым – әрле башым
Бедная голова – скромная голова

Ярлы кеше яманыр, яманыр да куаныр
Бедняк залатает дыры и будет рад

Юрганыңа карап аягыңны суз
Протягивай ножки по своей одёжке

Юрганыңа күрә аягыңны суз
По своему одеялу ноги протягивают

Эндри казнасы
Золотое дно

Хәерче кесәсендәге шикәр кебек шомарган
Гладкий, как сахарокв кармане бедняка

Хәерчегә җил каршы
Бедняку и ветер всегда в лицо

Хәрәм акча кесә тишә
Греховные деньги и карман продырявят

Харам килгән әрәм китәр
Легко пришло, легко и ушло / Что пришло греховно и уйдёт напрасно

Җире байның иле дә бай
У богатых земель истраны богатые

Җилдән килгән акча
Деньги из воздуха

Бәясе – сукыр бер тиен

Грош цена

Бу патшаның тәхете ни дә, бәхете ни
У этого богача что трон, что счастье

Байлык сөйдерер, ярлылык көйдерер
Богатство обрадует, бедность опечалит

Акча ул кысып – кымтым тотканны ярата
Деньги любят сжатый кулак

Теләнчегә якты чырай бирсәң, ямаулык сорар
Дай нищему с ноготок – попросит с лоскуток

Очсыз әйбер тиз туза
Дешевый товар быстро ветшает

Картаерга акча кирәкми
Чтобы состариться деньги не нужны

Йокы белән юк берга йөриләр
Бедность ходит вместе со сном

Ишле байгыш байны басар
Бедняки сообща одолеют и богача

Бәхетне акчага сатып алып булмый
Счастье не купишь

# Строение тела человека

Авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә
Что на зеркало пенять, коли рожа крива

Аягы җиргә тими
Витает в облаках

Алдыңнан артың яхшы
Скатертью дорога

Муен булса камыт табыла
Была бы шея, хомут найдется

Арык кеше – алчак, базык кеше – басымчак
Худощавый человек – ветреный, крепкий – кроткий

Иңе барның буе бар, буе барның сыны бар
Кто вширь – тот в рост, кто в рост – тот в стан

# Семья и родственные отношения

Акыллы ир хатынын яманламас
Умный муж свою жену не станет порочить

Ата-ана бердәм булса, балалары күркәм үсә
В дружной семье растут прекрасные дети

Ата – анасын хурлаган үзен хурлаган булыр
Оскорбить родителей – оскорбить себя

Аталы-аналы – алтын канатлы
Иметь отца и мать – иметь золотые крылья

Ата–бабалы кеше – тамырлы имән
Человек с предками, что дуб с корнями

Ашка аш, ташка таш
Око за око, зуб за зуб

Алма агачына, бала атасына охшар
Яблоко похоже на яблоню, ребенок – на отца

Ир беләк – хатын терәк
Муж – рука, жена – опора

Алма агачыннан ерак төшми
Яблоко от яблони недалеко падает

Һавада болыт бар, анада өмет бар
В небе есть облако, а в маме – надежда

Үз күлмәгем үземә якын
Своя рубашка ближе к телу

Әнисенә кара да – кызына кара, атасына кара да – улына кара
Смотри на мать – увидишь дочь, смотри на отца – увидишь сына

Яхшы хатын белән бер кайгы ярты кайгы, бер шатлык – ике шатлык
С хорошей женой и скорбь делится пополам и радости вдвойне

Хатын – муен, ир – баш, муен кайда борса – башы шунда борыла
Муж – голова, жена – шея, куда хочу, туда ворочу

Утыз улың булганчы, аксак ирең булсын
Вместо тридцати сыновей пусть будет муж хромой, но свой

Үзеңнеке үзәктә, яши бирсен тозакта

Свое всегда рядом, пусть учится жить в капкане

Улның ояты атага, кызның оятыанага
Позор сына – на отце, позор дочери – на маме

Туганыңнан бизмә, нәселең корыр
Не отрекайся от родных, иначе твой род исчезнет

Туган бар җирдә ярдәм бар
Где есть родные, там есть и помощь

Тату туганнар таштан койма корган
Дружные родственники из камня ограду сделают

Суы булган җир кадерле, иле булган ир кадерле
Та земля өенна, где есть вода, тот муж ценен, у которого есть страна

Матурлык туйда кирәк, татулык көнда кирәк
Красота нужна на свадьбе, а дружба каждый день

Карама үзенә, кара нәселенә
Смотри не на него, а на его род

Кияүдән кайткан кыз кайта килгән яудан яман
Сбежавшая жена – вернувшийся с боя предатель

Иргә ышанма, елгага таянма
На мужа не надейся и на реку не опирайся

Ирең юлдан язса – ярты өең калыр, хатының юлдан язса – бер-бернәрсәң да калмас
Сошедший с пути муж оставляет пол дома, сошедшая с пути жена – пустоту
Ирне ир иткән да хатын, чир иткән да хатын
И та, что возвеличила мужа – женщина, и та, что уничтожила – женщина

Ир – баш, хатын – муен
Муж – голова, а жена – шея

Ир уңган булса, хатын елдам була
Если муж дельный, то и жена проворная

Җан тартмаса, кан тарта
Не душа, так кровь тянет

Елыйсы килгән бала атасының сакалы белән уйный
Ребенок, который хочет плакать – играет с бородой отца

Брат братның көтү көткәненә рад
Родной брат рад помочь во всем

Башыңа бәла төшкәндә, туганыңны танырсың
Когда настигает беда – узнаёшь (вспоминаешь родственников)

Анаң үги булса, атаң үзеңнеке булмас
При мачехе и отец не родной

Ана күңеле – балада, бала күңеле – далада
Душа матери в ребенке, ребенка – в свободе

Ир какканны – мир кага
Сделанное мужем, обсуждается всем миром

Ир хакы – Алла хакы
Долг перед мужем – все равно что долг перед Богом

Дусның искесе, хатынның яңасы яхшы
Друзья хороши старые, а жена – новая

Ике тәкә башы бер казанга сыймый
Две бараньи головы в одном казане не уместить

Иптәшең сукыр булса – күзеңне йом
Закрой глаза на слепоту ближнего

# Язык

Әйттем исә кайттым
Сказано – сделано

Әйтер идем бер сүз – авызым син түз
Сказал бы одно слово, да попридержу язык

Бер әйт – берәгәйле әйт
Скажи один раз, но метко

Башка килгәне телдән килә
Дурная голова ногам покоя не даёт / Язык без костей намелет на семь волостей

Әйткән сүз – каккан казык
Сказанное слово, что вбитый кол

Аңа әйткәнче бер ташка әйтсәң, таш җанланыр иде
Даже камень ожил бы от таких слов

Аңламый сөйләгән авырмый үләр
Сказавший не зная, умрёт без мучений

Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы
Веревка хороша длинная, а слово – кроткое

Әйткан сүз – аткан ук, кире кайтарып булмый
Сказанное слово – выпущенная стрела, обратно не воротишь

Бала күздән, адәм сүздән зыянлый
Ребенка береги от зглаза, а взрослого от злого слова

Бака бакылдап, телчән такылдап туймас
Лягушка не наквакается, болтун не наговорится

Ана теле бер булыр
Родной язык единственный

Яхшы сүз – җан азыгы, яман сүз – баш казыгы
Доброе слово окрыляет, а плохое колом по голове

Усал тел кыш кебек, яхшы тел яз кебек
Злое слово как зима, доброе – как весна

Телеңне йотарсың
Язык проглотишь

Татлы тел тимер капканы ачар

Доброе слово и железные ворота откроет

Җылы сүз җан эретә
Доброе слово душу греет

Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр
Бережный к родному языку народ – будет ценным

Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел
Язык и полюбить и возненавидеть заставит

Сөйдергән дә тел, көйдергән дә тел
И радует язык, и обжигает язык

Сүзең көмеш булса, эндәшмәвең алтын
Если слово твое – серебро, то молчание – золото

Су һәр нәрсәне агарта ала, әммә йөз карасын агарта алмый
Вода все смоет, кроме настроения

Егет сүзе бер булыр
Молодец своему слову верен / У молодца слово одно

Бинең авызы кыек булса да, сүзе туры
У богача хоть рот и кривой, да слова прямые (правдивые)

Син әйтмәдең, мин ишетмәдем
Ты не говорил, я не слышал

Сорамаган сүзгә җавап бирмиләр
Нет вопроса – нет ответа

Сүз иясе белән йөрми
Слово с хозяином не ходит

Дөрес сүзгә җавап юк
Правдивому слову нет опровержений

Сүз сөйләсән, уйлап сөйлә
Если говоришь, делай это обдуманно

Сүзе балдай, күңеле боздай
Слова как мед, а сердце как лед

Сүз эзләп күршегә керми
За словом в карман не полезет

Оста янында кулыңны тый, галим барда телеңне тый
Среди мастеров сдерживай руки, среди ученых – язык

Ният иткән – морадына җиткән
Намерившийся – достигнет цели

Картлар сүзен кар басмас
Слово старейшин снег не запорошит

Кемнең кай җире авыртса, шуны сөйләр
У кого что болит, то о том и говорит

Акыллы сүз алтыннан кыйбат
Толковое слово дороже золота

Акылы кысканың – теле озын
Глупый славится длинным языком

Кешенең теле аңа дан да китерә ала, хурлык та китерә ала
Человеческий язык может принести как славу, так и унижение

Кеше сүзе – кеше үтерә
Слово может и убить

# Животный мир

Аттан ала да туа, кола да туа
От лошади и чалый родится, и саврасый

Аты бер булса да, заты башка
Название одно, а качество разное

Атым юк аранда – кайгым юк буранда
Нет лошади в стойле, нет проблем в буран

Аулак күлгә бака хуҗа
В озере без царя правит лягушка

Азыклы ат арымас
Сытая лошадь не устанет

Кырмыска канатланса үлә
Окрылившийся муравей обречен на смерть

Йөгерек атка камчы кирәкми
Быстрой лошади плеть не нужна

Иртәгә өчен ишәк кайгырыр
Насчет завтра переживает только осел

Имәндә икән чикләвек!
Вот где собака зарыта

Ишкәнсең икән ишәк чумарын
Метил в ворону, попал в корову / Ну и натворил ты

Иртәгәге тавыктан, бүгенге йомырка артык
Сегодняшнее яйцо лучше завтрашней курицы

Зыянчы песинең күзе елтырый
У нашкодившего кота глаза блестят

Елан аягын кискән
Видавший виды / Прошедший огонь и воду

Елан йоклар, дошман йокламас
Змея уснет, а враг нет

Елан койрыксыз булмас, би боерыксыз булмас
Как нет змеи без хвоста, так и хозяина – без приказов

Елан чаккан, җептән куркыр

Ужаленный змеей и веревки испугается / Пуганая ворона куста боится

Дөя сөрлегүгә карап кәрван туктамый
Оттого, что один верблюд спотыкается, караван не остановится / Собака лает, караван идет

Дуңгыздан бер кыл
С паршивой овцы хоть шерсти клок

Дүрт аяклы ат та абына
Конь о четырёх ногах да спотыкается

Бер карлыгач яз ясамый
Одна ласточка весны не делает

Балык башыннан чери
Рыба гниёт с головы

Бүре баласы бүреккә салсаң да урманга карый
Сколько волка не корми – все равно в лес смотрит

Бүре баласын үзе карасын
Волчёнка пусть волк сам воспитывает

Бүредән курыккан урманга бармас
Волков бояться – в лес не ходить

Бер буклы күтле сыер бөтен көтүне буклый
Паршивая корова все стадо портит

Бер тычкак сыер бөтен көтүне буклый
Паршивая овца все стадо портит

Бер елга куян тиресе дә чыдый
Один год и кроличья шкура выдержит

Баткак бакага килешер
Грязь жабе к лицу

Аснусыз (тәрбиясез) этнең койрыгы озын (койрыгын кыскартырга кирәк)
У невоспитанной собаки и хвост длинный (хвост нужно укоротить)

Арслан булып арслан да үзеннән биек сикерә алмый
Даже лев не может прыгнуть выше своей головы / Выше головы не прыгнешь

Аның әтәче дә күкәй сала
У него и петух яйца несёт

Агач җимеше белән, кеше эше белән

Дерево дорого плодами, а человек делами

Дүрт аяклы ат та абына
Лошадь о четырёх ногах, да спотыкается

Дәрьядагы балык сатылмас
Не пойманная рыба не продаётся

Бер су белән генә торып булса, балык кармакка капмас иде
Если бы рыба могла питаться лишь водой, она бы не клевала

Биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян
Пользы на копейку, а убытка на десять

Ашаган малда өмет бар
На скотину, которая ест, есть надежда

Ашаган җиренә сыер да кайта
К кормушке и корова возвращается

Аюны да биергә өйрәтәләр
И медведя научат танцевать

Этләр талашып, чәйнәшеп танышалар
Собаки знакомятся в драке

Чучка сарык булмый
Свинья овцой не станет

Чебешләрне көз көне сайныйлар
Цыплят по осени считают

Чебен тисә чер итәр
Муха укусит-уже запищит

Тауны тәкә сөзеп җимерә алмый
Баран горы не разрушит

Сукыр тавыкка бар да бодай
Слепой курице все пшено

Сигез сыер асраганчы, симез сыер асра
Вместо семи коров, заведи одну мясистую

Сакның сагы ятар, саксызның башы ятар
Осторожного коня и зверь не берет

Кәҗә дә мал, баҗа да туган
И козел – скотина, и свояк – родственник

Кәҗәсе түгел – мәзәге кыйбат
Дорог не подарок, а внимание/Дорога цена не козла, а шутки

Караңгыда ялтыраганчы, яктыда калтыра
Лучше днем дрожать, чем ночью блестеть

Карга каргага “йөзең кара” дигән ди
Ворон ворону глаз не выклюет

Карга каркылдап кына кар яумый
От карканья вороны снега не пойдет

Карга карганың күзен чукымас
Ворон ворону глаз не выклюет

Качкан балык зур була
Не пойманная рыба всегда большой кажется

Балык сусыз торалмый, кеше дуссыз торалмый
Рыба не может без воды, человек – без друга

Бар чагында – бүредәй, юк чагында – шүредәй
Когда есть – волк, когда нет – шпилька / Когда есть – так густо, нет – так пусто /

Былтыр кысканга быел кычкырмыйлар
О прошлогоднем снеге сейчас не жалуются

Ала каргадан алачагың булсын
От пего ворона пусть будет толк

Эт авызыннан сөяк алып булмый
Кость из пасти собаки уже не заберёшь

Эт күңеле – бер сөяк
Радость собаки в одной косточке

Эт симерсә, иясен талый
Разжиревшая собака и хозяина укусит

Эт тапса – аерым ашар, егет тапса – бергә ашар
Найдет пес – съест сам, человек найдет – поделится

Эт чаба дип бет чаба
Блохи скачут вслед за собакой

Азыклы ат арымас
Сытая лошадь не устанет

Эт өрер – бүре йөрер
Собака лает, ветер несёт / Собака лает, а волк идёт

Этсез куян тотып булмый
Без собаки зайца не поймать

Тычканга – үлем, песигә – көлке
Мыши – смерть, а коту – смех

Энҗене эт муенына такмыйлар
Жемчугана собак не надевают

Энҗенең эт муенында кадере юк
Жемчуг на шее собаки ценности не имеет

Эт авызына бер сөяк
Собаке лишь бы кость

Эт оясында көчле
Собака сильна в своей конуре

Ходай бүрегә бәхет бирсә, тешен сындырып бирә ди
Судьба, даруя волку счастье, делает его беззубым

Уртак малны эт тә җыймас
Общую скотину и собака не соберёт

Салмаган чебеш кыткылдамый
Не высиженный птенец не щебечет

Ат – тауда, егет яуда сынала
Лошадь проверяетсяна горе, а молодец – в битве

Ат азгыны тайга иярә
Дурной конь плетётся за жеребцом

Ат алсаң – тешен кара, дус булсаң – эшен кара
Выбирая лошадь – проверяй зубы, выбирая друга – дела

Ат кешнәшеп, әдәм сөйләшеп таныша
Лошади знакомятся ржанием, а люди – разговорами

Ат яхшысы – арканда, ир яхшысы – тарханда
Лучшего коня держат на аркане, а лучшие мужчины в свободе

# Труд

Аягың тәпелдәмәсә, авызың чәпелдәми
Не потопаешь – не полопаешь

Агач жимеше белән, кеше эше белән
Дерево славится плодами, человек – делами

Аз сөйлә, күп эшлә
Мало говори, больше делай

Аягың җиңел булсын
Пусть нога будет легкой

Калган эшкә кар ява
Отложенное дело снег запорошит / Отложенное травой зарастёт

Ашыккан – ашка пешкән
Поспешить – людей насмешить

Һөнәрсез кеше – көн курмәс
Человек без ремесла – человек без будущего

Һөнәремнең бәхете – кулымда
Счастье мастерства – в моих руках

Кем эшләми – шул ашамый
Кто не работает – тот не ест

Ике кулыңа бер эш, иртән тор да кереш (ябыш)
Одна работа в две руки, вставай с рассветом и крути

Башланган эш – беткән эш
Как начал дело, так и закончишь / Начатое дело – законченное

Аяклы, куллы кешегә хөнәр кирәк
Человеку с руками и ногами нужно ремесло

Тырай тибеп йөрү
Гонять лодыря / Бить баклуши

Телеңә салынып эшеңне онытма
За пустой болтовней не забывай дела

Киңәшле эш таркалмас
Дружная работа не распадётся

Тирләп эшләсәң, арыш икмәге дә тәмле

После тяжелого труда и ржаной хлеб вкусный

Сүз белән мактанганчы, эш белән мактан
Хвались не словом, а делом

Син сөйләмә, эшең сөйләп торсын
Пусть говорит твоя работа, а не ты

Акыллы – эше белән, ахмак – сүзе белән
Умный славится делом, а глупый – словом

Сөйләп күрсәткәнче, эшләп күрсәт
Вместо слов, покажи делом

Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың
Усердно работаешь – вкусно ешь

Тырышкан табар, ташка казык кагар
Старательный и найдет, и гвоздь в камень вобьет

Тама-тама күл булыр, тузан – тузан тау булыр
Капля за каплей будет озеро, пылинка за пылинкой – гора наберётся

Өй дәрте – дию дәрте
Уют дома – результат труда

Олы күтәреп бәләкәй бәрә
Много всего говорится, да мало в дело годится

Күз курка – кул йолка
Глаза боятся, а руки делают

Көндезге эш кичке эштән көлер
Дневной труд над вечерним смеётся

Курыксаң – эшләмә,эшләсәң – куркма
Боишься – не делай, делаешь – не бойся

Кырык эш кырык җирдә теркәлеп ята
Сорок дел в сорока местах брошены

# Человеческие отношения

Абзар сатып алма, күрше сатып ал
Выбирай не дом, а соседа / Выбирай не сарай, а соседа

Агай-эне тартышы – туй бүләге ертышы
Ссора родни – делёж свадебного подарка

Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар
Отделившихся съест медведь, разделившихся – волки

Арага шайтан кергән
Между ними черт поселился

Аерылмас дустыңа онытылмас сүз әйтмә
Не говори близкому другу слов, которые не забудутся

Аз кайгыны аш баса, күп кайгыны дус баса
Малое горе заедается пищей, большое – исцеляется друзьями

Акыллы дошманнан курыкма, ахмак дустан курык
Не бойся умного врага, остерегайся глупого друга

Ара өзек булса, кардәшлекякын була
Счет чаще – дружба слаще

Араларыннан су да үтми
Водой не разольёшь

Араларыннан җил дә үтми
Между ними и ветер не пройдёт

Һәр көлгәнне дусым димә, һәр ачуланганны дошманым димә
Не каждый улыбающийся – твой друг, и не каждый рассердившийся – твой враг

Үзеңдә булмаса, күршеңдә булсын
Если не у себя, то хоть у соседа пусть будет

Үз капка алдыңның карын күрше капкасына көрәмә
Не греби снег к чужим воротам

Өең тар булса, дөньяның киңлеге беленмәс
В тесном доме широта мира незаметна

Кунак булсаң тыйнак бул
Если ты гость, будь скромнее

Өеңдәге хәлне күршедән сора

Что творится дома лучше знает сосед

Яңа себерке шәп себерә
Новая метла чисто метет

Яңа дус тап, әммә искесен дә ташлама
Найди нового друга, но и старого не бросай

Чын дус йөз – елдан соң да дус булыр
Настоящий друг и через сто лет останется таковым

Тол хатынның көне – таң атмаган төне
День вдовы, что та же ночь без рассвета

Тимерчегә күмерче юлдаш
Кузнецу угольщик – напарник

Ташның олысын дус ташлый
Самый тяжёлый камень бросает друг

Тау тауга кушылмас, әдәм әдәмгә кушылыр
Гора с горой не сойдётся, а человек с человеком может

Сер күтәрә алмаслык кешегә – сер сөйләмә
Не доверяй тайну тому, кто эту ношу не вынесет

Мең дус та – аз, бер дошман – күп
Тысячи друзей может быть мало, а врага и одного – много

Күрше ашы – күңел хушы
Еда соседа – отрада для души

Күрше күршедән иртә торырга өйрәнә
Сосед учится вставать рано у соседа

Иптәшең сукыр булса – күзеңне йом
Если друг слеп – закрой и ты глаза

Күрше күрше башына тузан какмый
Сосед не стряхивает пыль на голову соседа

Моның белән ботка пешереп булмый
С ним каши не сваришь

Кеше ашы тәмле була
Чужое угощенье бывает вкусным

Йөз сом акчаң булганчы, йөз дустың булсын
Не имей сто рублей, а имей сто друзей

Исәр ипкә килмәс. Юләр юньгә килмәс
Дурак к порядку не придет, а глупый не придет к толковому

Иске дус – иярләгән ат
Старый товарищ – осёдлая лошадь

Ике яхшы дошман булышмас
Два хороших врага не помогут

Ике яңа дустан бер иске дус яхшырак
Один старый друг лучше двух новых

Үги үз булмас
Приемный родным не станет

Дошман алдында, эчең еласа да, тышың көлсен
Перед врагом, даже если сердце плачет, лицо пусть смеётся

Дошман серемне белмәсен дисәң, дустыңа да сереңне әйтмә
Если не хочешь, чтобы враг узнал, не говори и другу

Дошман сигез – без унике
Врагов восемь, а нас двенадцать

Дошманкырмыска булса да, фил булып күренер
Враг даже с муравья, будет казаться слоном

Дошманны куй дип уйлама, бүре дип уйла
Врага представляй не овцой, а волком

Дошманның азы да күп
Даже пары врагов много

Дошманыңа үлем теләгәнче, үзеңә гомер телә
Вместо смерти врагу, желай себе долголетия

Дошманыңа әйтергә ярамаганны дусыңа да әйтмә: аның иртәгә дошман булуы бар
То, чего не скажешь врагу, не говори и другу: завтра он может стать врагом

Дус – акчадан кыйммәт
Друг дороже денег

Дус артыңда мактар, дошман алдыңда мактар
Друг будет хвалить в спину, а враг – в лицо

Дус аткан таш баш ярмый
Пущенный другом камень голову не пробьёт

Дус бар, дошман да бар
Есть друг, есть и враг

Дус башка, дошман аякка карар
Друг смотрит на голову, а враг – на ноги

Дус беленер авырлыкта, ир беленер батырлыкта
Дружба познаётся в беде, а муж – в храбрости

Дус дус булсын, хисабың дөрес булсын
Дружба дружбой, а счет пусть будет верным

Дус дус өчен мал бирер, яу килгәндә җан бирер
Друг за друга отдаст скоину, а в бою – жизнь

Дус көйдереп әйтер, дошман көлдереп әйтер
Друг скажет прямо, а враг – рассмешив

Дус – ишле булыйм дисәң, кинә тотма
Хочешь быть достойным другом, не таи злобу

Дуслар акчаң барда күп була
Друзей бывает много в богатстве

Дуслар хәтерен калдырсаң, дошман хәтерен табарсың
Обидишь друга – угодишь врагу

Дусларның йөзе дә аз, дошманның берсе дә күп
Друзей и 100 мало, а врага и одного много

Дуслык ашаганда беленми, эшләгәндә беленә
Дружба познается не в трапезе, а в работе

Дусны табу җиңел, саклавы авыр
Друга легко найти, но сложно сохранить

Дусның дуслыгы өч көннән түгел, өч елдан соң беленер
Дружба познается не через три дня, а через три года

Дуслык – зур байлык
Дружба – большое богатство

Кош канаты белән, кеше – дуслык белән көчле
Птица сильна крыльями, а человек – дружбой

Дуслык тау күчерә
Дружба горы двигает

Гаепсез аш эзләмә – ач калырсың, гаепсез дус эзләмә – ялгыз калырсың

Не ищи работу без изъянов – останешься голодным, не ищи идеального друга – останешься один

Берни белмәгән кеше һәрвакыт боек булыр
Ничего не знающий человек всегда будет великим

Надан белмәсә дә кычкыра
Дурак кричит, даже не зная

Бозылышкан дус дошманнан яман
Бывший друг страшнее врага

Биргәндә дус, алганда дошман
Когда даешь – друг, когда забираешь – враг

Бер күргән – белеш, ике күргән – таныш, өченче күргән – кардәш
С первого взгляда – знакомый, со второго – приятель, с третьего – друг

Ерак кардәштән тату күрше яхшы
Хороший сосед лучше дальнего друга

Икәү белгәнне ил белә
То, что знают двое – знает весь свет

Балык сусыз торалмый, кеше дуссыз торалмый
Рыба не может без воды, человек не может без друга

Бердәмлектә көч
Сила в единстве

Бергә эшләсәң, авыр эш тә җиңел
Вместе и тяжелый труд лёгок

Бер казага ике җәза юк
За один проступок не бывает двух наказаний

Бер караганда ал да гөл, бер караганда җил-давыл
С одной стороны – ягода – малина (всё прекрасно), с другой – буря
Бер кораллы мең коралсызны җиңгән
Один вооружённый победит тысячу безоружных
Дусын сакламаган дошманга эләгер
Тот, кто не ценит друга, попадёт в лапы врага

Дусың авырса, син дә ыңгыраш
Если друг болен – плохо будет и тебе

Дусың дус булып калсын дисәң, аңа баш булма, иш бул
Хочешь сохранить дружбу – будь ему товарищем, а не головой

Дусыңнан аерыласың килсә, бурычка бир
Хочешь лишиться друга – дай ему в долг

Күрше капкасын какма, үзеңнекен сындырырлар
Не стучи в двери соседа, свои сломают

Күршегә кереп торасы түгел
У соседей нестоит и спрашивать

Күршегә онга кермәсәң дә, көлгә керерсең
К соседям не за мукой, так за золой

Күршедә пешәр, безгә дә төшәр
Готовится у соседей и нам перепадёт

Күршелек кардәшлектән якын
Соседство ценнее дружбы

Күршеләргә килсә туй, син дә капкаңны ачып куй
Если у соседей свадьба и ты ворота отвори

Күршеләре белән тату яшәмәгән кешене берәү дә хөрмәтләми
Того, кто в раздоре с соседями, никто не уважает

Китап – белем чишмәсе
Книга – источник знаний

Күршесенә ышанган – ач кунган
Понадеялся на соседей – остался голодным

Күршең бай булса да, җигәреңә тай булсын
Даже если сосед богат, пусть будет свой запряжённый жеребец

Күршең бай булса, тавыгың тук булыр
Сосед богат – куры сыты

Күршең белән яман торыйм дисәң, кәҗә асра
Хочешь враждавать с соседом, заведи козу

Күршең үзеңнән яхшы булсын
Пусть сосед будет лучше тебя

Күршеңә бер сыер теләсәң, үзеңнеке ике булыр
Желай соседу корову, у самого две появится / Желай соседу лучшего

Курыкканга куш күренә
У страха глаза велики / У труса в глазах двоится

Курыкканны эт абалый

Трусливого и собака не пропускает

Кыз мактала эш белән, түгел энҗе теш белән
Девица славица работой, а не жемчужными зубами

Корымнан корым йогар, начар дустан сөрем йогар
От угля дым, от плохого друга – головная боль

Коры ботка – су белән, коры дуслык – сүз белән
Густая каша из-за воды, скупая дружба из-за слов

Киңәшле җыен таркалмас
Дружный сход не разойдется

Кешенең иң зур дәүләте – чын дусы
Самое большое государство – честный друг

Кешенең кемлеген беләсең килсә, иптәшләренә кара
Хочешь узнать человека, спроси кто его друг

Кеше тычты – күтем кызды
Чужой нагадил, а вскипел я

Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә
Чужие заботы сна не лишают

Кешегә баз казыма – үзең төшәрсең
Не копай яму другому, сам в неё угодишь

# Дети

Бал татлы – балдан бала татлы
Сладок мёд, а дитя слаще мёда

Бала итәктә чакта сөйдерә, итәктән төшкәч көйдерә
Ребенок пока на коленках радует, а спустившись – огорчает

Ата баласы хата булмас
Человеческое дитя ошибкой быть не может

Еламаган балага ими каптырмыйлар
Дитя не плачет – мать не разумеет

Бишектәге йөзгә төрләнә
Пока повзрослеет – сто раз изменится

Ризыксыз бала тумый
Каждый ребенок рождается с местом под солнцем

Аталы бала – ардаклы бала
Ребенок с отцом – ласковый ребенок

Аталы бала аркалы, аналы бала иркәле
Папин ребенок – кремень, мамин – неженка

Бала күздән, адәм сүздән зыянлый
Ребенок проказничает от взгляда, человек – от слова

Балалы өй – базар, баласыз өй – мазар
Дом с детьми – базар, а без детей – кладбище

Баласы елак булса, анасы чирак була
У плаксивого ребёнка и мать проворна

Бишектәге бишкә төрләнә
Лежащий в колыбели изменится еще пять раз

Баласыз хатын – ботаксыз агач
Женщина без дитя, словно дерево без веток

Бер кашык су белән йотарлык
Хватит запить ложкой воды

Бер башны туйдырмаган ике кул – корысын
Пусть отсохнут две руки, не прокормившие и одну голову

Бер бала – мең бәлә

Один ребенок – тысяча неприятностей

Белмәгәннең беләге авыртмый
На нет и суда нет / У незнающего голова не болит

Балам баласы балдан да татлы
Внуки и мёда слаще

Балалы кеше – бай кеше
Человек с детьми – богатый человек

Ашаганда колагың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен
Во время еды пусть уши шевелятся, а во время работы – пусть сердце поёт/ Есть надо с аппетитом, а работать с огоньком

# Ум

Акыл базарда сатылмый
Ум не рынке не купишь

Акыл яшьтә түгел, башта
Ум не в возрасте, а в уме

Акылың булса ачу саклама
Умный обиды не таит

Ачулы башта акыл юк
В злой голове ума нет, не проживешь добром век

Акылга утырырга
Браться за ум

Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс
То, что не вошло с молоком матери, с молоком коровы уже не войдет

Белемле кыз – бирнәле кыз
Образованная девушка – девушка с приданым

Акыллы дошман надан дустан яхшырак
Умный враг лучше глупого друга

Акылы төштән соң
Задним умом крепок

Акыллының уендагы акылсызның телендә
Что у умного на уме, у глупого – на языке

Өйрәнмичә чабата да үреп булмый
Без ума и лапти не свить

Өйрәнү бервакыттада соң түгел
Учиться никогда не поздно

Өйрәтсәң, аю да биергә өйрәнә
И медведя можно научить танцевать

Мәктәп юлы – мәңгелек
Школьная дорога – вечность

Эшләгәнең кеше өчен булса – өйрәнгәнең үзең өчен
Работаешь – для других, учишься – для себя

Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска

У баб волосы длинные, да ум короток

Хатын-кызга акыл кырыктан соң керә
Женщине мудрость приходит после сорока

Уйнап сөйләсәң дә уйлап сөйлә: тел көферлегенә төшәрсең
Даже в шутку, говори подумав: впадешь в богохульство

Уйнап әйтсәң дә уйлап әйт
Даже играя, говори подумав

Уку – энә белән кое казу
Ученье – то же, что рыть иголкой колодец

Китап – якын сердәш
Книга – близкий друг

Күп беләсе килгән кеше күп йокламый
Кто хочет много знать – тот долго не спит

Кешенең акылы сүзеннән билгеле
Ум человека видно по его словам

Китап – тормыш көзгесе
Книга – зеркало жизни

Күп белсәң – тиз картаерсың
Много знаешь – скоро состаришься

Китап – белем чишмәсе
Книга – источник знаний

Көче булган берне егар, белеме булган меңне егар
Сильный одного победит, а умный – тысячу

Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар
По одежке встречают, по уму провожают

Белемле кеше югалмас
Человек со знаниями не пропадёт

Бүләк зур булмас, укыган кеше хур булмас
Подарок не будет большим, умный не осрамится

Белгән кеше эшли, белмәган өйрәтә
Знающий – делает, не знающий – учит

Башына тай типмәгән
В своем уме / Пока не потерял разум

Дөньяда иң изге урын – мәктәп, иң зур байлык – белем
Самое священное место на земле – школа, самое большее богатство – знания

Бүгенге көндә йомырка тавыктан да күп белә
Сегодня и яйцо знает больше курицы

Бер кешедә бер акыл, халыкта мең акыл
В человеке – один мозг, в народе – тысяча

Белмәү гаеп түгел – белергә теләмәү гаеп
Вина не в незнании, а в нежелании узнать

Беләге бар берне егар, белеме бар меңне егар
Рукастый ударит один раз, умный – тысячу

Күп укыган күп белер
С книгой поведешься – ума наберешься

Кояш җирне яктырта, уку кешене
Солнце освещает землю, ученье – человека

Керәшеннең акылы – керәле дә чыгалы
Человеческий разум – приходит и уходит

Галим белән надан аермасы – карга белән былбыл аермасы
Разница между учёным и глупцом – как между соловьём и вороной
Галим белсә сорый, надан белми дә, сорамый да
Ученый, зная – спросит, глупец и не знает, и не спрашивает

Галимнең бер көне наданның бөтен гөмеренә тора
Один день ученого, что вся жизнь глупца

Галим уйлар, надан ышаныр
Учёный подумает, глупец сразу поверит

Галим булу җиңел, әдәм булу читен
Легко стать учёным, трудно быть человеком

Аек башта – аек акыл
В трезвой голове трезвый ум

Укыган укыр, укымаган күрә сукыр
Читающий читает, нечитающий и имея глаза слеп

Ата гыйлеме белән галим булып булмый
Знаниями отца учёным не станешь

Уку кешене күзле итә

Учеба открывает человеку глаза

Белем – бәхет ачкычы
Знания – ключи от счастья

Сакал агармыйчы акыл керми
Пока борода не поседеет – ум не зайдёт

Надан кеше – сукыр тавык
Глупый человек – слепая курица

Надан кеше – яман кеше
Глупый человек – злой человек

Матурга да акыл артык булмас
Красавице и ум не помешает

Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк
Красота нужна насвадьбе, а ум – ежедневно

# Еда

Аштан олы булып булмый
Хлеб – всему голова

Ашым аш, суым су түгел
Не идет на ум ни еда, ни вода

Агылый белән тогылый
Водой не разольешь / Неразлучные друзья

Кунакны ипи – тоз, якты йөз белән каршылыйлар
Гостей хлебом – солью и приветливым лицом встречают

Майсыз коймак шумый шул
Без масла и блин не скользит

Май чүлмәге тышыннан билгеле
Масляный горшок видно сразу

Ит күрмәгәнгә үпкә тансык
Когда нет мяса и лёгкие желанны / На безрыбье и рак рыба

Тозсызны күзсез дә сизә
Пресную еду и слепой чувствует

Күпкә китсә бал да ачы
В излишке и мёд горький

Бер тарыдан ботка пешми
Из одного просяного зёрнышка каши не сваришь

Ашның тәме тоз белан, мәҗлес яме сүз белән
Блюдо вкусно солью, застолье славится беседой

Ашаган табагыңа төкермә
Не плюй в миску, из которой ешь

Үз күчтәнәч ашаган кешенең гомере озын була
Кто испробует свой гостинец, продлевает себе жизнь

Ач иманны белмәс, яшь заманны белмәс
Голодный не знает веры, молодой не знает времени

Ач тамагым – тыныч колагым
Лучше быть голодным, чем слушать упрёки

Ач хәлен тук белмәс

Сытый голодного не разумеет

Ачлыкка түзеп була, суыкка – юк
Голод выдержать можно, холод – нет

Ачның ачуы яман
Злость голодного страшна

Аш ашка – урыны башка
Для каждой пищи в желудке есть отдельное место

Ашаганда дус күп, башка төшсә берсе дә юк
За столом все друзья, но когда вы идете вниз – нет ни одного

Ашау байдан – үлем ходайдан
Еда от богача, смерть – от Бога

Ашка каршы – аш, ташка каршы – таш
Око за око, зуб за зуб

Ашны бергә пешерсәң, куе була
Вместе сваренный суп получится гуще

Ашны күрсәң кадер тот, дусны күрсәң гадел тот
В еде видь ценность, в дружбе – будь справедлив

Күгәрчен сөте генә юк
Нет только голубиного молока

Күкәй эчендәге сары кебек
Желтый словно желток

Дөнья җәе белән, коймак мае белән
Жизнь славится летом, блины – маслом

Ашым аш, суым су түгел
Не идет на ум ни еда, ни вода

Агылый белән тогылый
Водой не разольешь

Бер тарыдан ботка пешми
Из одного горошка проса каши не сваришь

Ашаган белми, тураган белә
Знает не тот, кто вкушает, а тот, кто нарезает

Сыпы (аш сайлаучы, менгел) суган ашамас, күрсә – кабыгын да куймас
Привереда на людях и лук не съест, а проголодавшись и кожуры не оставит

# Природа

Ай гел болыт артында гына тормый
Луна не находится все время за тучей

Ай якты да, җылытмый
Луна светит, да не греет

Ай яктырткanда, йолдыз күренми
При луне звёзд не видно

Ай – тулгач кителә
Луна уходит в полнолуние

Аяз көндә яшен сугар
Гром ударит в ясную погоду

Җыен йолдыз җыелса да, яктылыгы айдай юк
Даже если звёзды соберутся, света как от луны не будет

Аяз көннең яшененнән курык
Бойся грозы в ясный день

Язның бер көне ел туйдыра
Один весенний день год кормит

Ләйсән суын җиде ел сакласаң да, энҗегә әверелми
Даже если хранить весеннюю воду семь лет –в жемчуг она не превратится

Ләйсән – рәхмәт яңгыры
Первый весенний дождь – дождь благодарности

Көн явым – ят та юрганың ябын
В дождливый день ляг и укройся одеялом

Кояш барда йолдыз күренми
При солнце и звёзд не видно

Кояш бик зур да, аны капларга кечкенә болыт җитә
Солнце огромно, но закрыть его достаточно и маленького облака

Кояш кермәгән өйгә врач керер
В дом, куда не заходит солнце, войдет лекарь

Кояш куянга атланган чак
Время, когда солнце верхом на зайце (на рассвете)

Санаулы көн тиз үтә

Считанные дни быстро проходят

Кояш та тапсыз булмый
Даже на солнце есть пятна

Кояш югында ай да яктырта
Когда нет солнца, и луна светит

Кояш юк – көн юк, көн юк – тереклек юк
Нет солнца – нет дня, нет дня – нет жизни

Кояшка балчык атма, пычрагы үзеңә төшәр
Не кидай грязь на солнце – сам испачкаешься

Кояшны култыгыңа яшерә алмассың
Солнце за пазухой не скроешь

Кояшның кадере баегач сизелә
Солнце ценится после заката

Коры җирдә чана да шумый
На сухой земле и сани не катятся

Килегә салып су төймиләр
Воду в ступе не растолочь

Килмәгән яңгырдан курку
Бояться дождя, которого нет

Кичүсез елга юк, батыр җиңмәс дошман юк
Непроходимой реки не существует, непобедимого врага нет

Кара суык кардан яман
Черный холод страшнее снега

Кайда су чыкса, коены шунда казыйлар
Колодец роют там, где есть вода

Кара җиргә кар яуса, карны күрү бер зәвык; кара җирдән кар китсә, җирне күрү берзәвык
Увидеть на черной земле первый снег – радость, как и увидеть черную землю после снега

Йомшак агачны корт баса
Мягкое дерево быстро прогнивает

Йөргән таш шомарыр, тик яткан таш мүкләнер
В движении камень шлифуется, а неподвижный – замшеет

Иртәнге яңгыр төшкә хәтле
Утренний дождь идет до обеда

Имгәк аяк астында
Беда ходит под ногами

Икмәк – илдән, су – күлдән
Хлеб от земли, а вода – от озера

Җидегән йолдыз җиде әйләнә, Тимерказык урынында
Медведица вращается по семь раз, а Полярная звезда всегда на месте
Җил агач башыннан, бәлә әдәм башыннан йөри
Ветер по верхушкам деревьев, а беда по людским головам ходит

Җил искән якка авырга
Падать туда, куда клонит ветер

Җил исми яфрак селкенми
Без ветра листья и не шелохнутся

Җил кай якка иссә, камыш шул якка борылыр
Куда дует ветер, туда камыш и повернётся

Җил кайссы яктан исә, ул да шул яктан кисә
Куда ветер подует, туда и он прибудет

Җил чәчсәң, давыл урырсың
Посеешь ветер, пожнешь бурю

Җил җелеккә үтәр
Ветер до мозга костей

Җил җилләми, томан ачылмый
Без ветра туман не рассеится

Җил-яңгыр тидермәү
Защитить от ветра и дождя

Җилгә каршы төкермә, битеңә төшәр
Не плюй против ветра, испачкаешься

Җилгә сәнәк белән каршы тормыйлар
Против ветра с вилами не стоят

Ерактагы кояш җылырак
Дальнее солнце теплее

Ерактагы су белән сусын канмый
Дальней водой жажду не утолишь

Елга күпме боргаланса да, диңгезгә төшәр

Река сколько бы не извивалась – попадает в море

Елганың башы комлы булса, тамагы да комлы була
Если исток реки илистый, то и продолжение такое

Дәрьяга яңгыр яуганнан ни файда
Потоку реки от дождя нет толка

Болганган су тирән күренер
Мутная вода кажется глубокой

Болганчык суда балык тотарга яхшы
В мутной воде рыба легко ловится

Болыт берексә – күк күкрәр, халык берексә – җир тетрәр
Если сплотится туча – гремит небо, если сплотится народ – содрогается земля

Болытсыз яңгыр булмас
Без тучи дождю не бывать

Бик шәп аккан чишмәнең башы якын була
У быстрого ручья устье близко

Бер тамчыдан диңгез булмый
От одной капли моря не будет

Бер болыттан боз да явар, кар да, яңгыр да явар
Из одной тучи пойдет и лёд, и снег, и дождь

Батып барган кояш туып килгән айга кырын карый
Заходящее солнце на восходящую луну косо смотрит

Аның кышкөнне кар алалмассың
У него и снега зимой не выпросишь

Җилдән килгән, җилгә киткән
Легко пришло, легко уйдёт

Җиле булгач, бураны да булыр
Есть ветер, значит и буря будет

Җилне төтен кумый, җил төтенне куа
Ветер гонит дым, а не дым ветер

Давыл алды тын була
Затишье наступает перед бурей

Давыллы болытның явымы аз
От тучи с ураганом дождь слабый

Җир астыннан йөргән еланны да сизәләр
Замечают даже ползающую под землей змею

Җир астыннан юл булмас (ягъни үлгәнче күрешеп калырга)
Под землей не будет дороги (т.е. нужно увидеться, пока еще живы)

Җир бастырыгы – тау, тау бастырыгы – таш
Землю подпирает гора, а гору подпирает – камень

Җир безне басканчы, без җиргә басып калыйк
Пока земля не наступила на нас, давайте мы по ней будем ступать

Җир чокырсыз булмас, урман киексез булмас
Земля без ям не бывает, а лес – без дичи

Дулкыннарга эләккәч таш та шомара
Даже камень полируется под волнами

Диңгез янында кое казымыйлар
Колодец рядом с морем не роют

Диңгездә су да кыйбат
На море и вода дорогая

Диңгездән чыктым, коега баттым
Из моря вышел, в колодце застрял

Диңгезне шырпы белән болгатып булмый
Море спичкойне замутишь

Диңгезнең дә чиге бар, елганың да яры бар
И у моря есть причал, и у реки – берег

Яңгыр – бай йөрәген янды
Дождь – встревожь сердце богача

Яңгыр көтсәң, кар явар
Ждешь дождь – будет снег

Яңгыр яуганда чиләгеңне тотып кал
В дождь успевай держать ведро

Яңгыр яуса – ялкауга ял
Дождливый день – ленивому отрада

Чыланган яңгыр тамчысыннан курыкмас
Мокрый дождя не боится

Яңгырдан соң тузан да басыла
После дождя и пыль оседает

Шаулы яңгыр тиз үтәр
Крупный дождь долго не идёт

Шәп яуган яңгыр җиргә сеңми
Сильный дождь землю не промочит

Чыландык та киптердек, яңгыр безне нишләтсен
Как вымокли, так и высохли, дождь нам не помеха

Чык суы матур булса да, сусын кандыра алмый
Роса красива, да жажду не утоляет

Чыкмаган кояшка кызынма
Не грейся не взошедшим солнцем / Тешиться несбыточными надеждами

Тамчы тама-тама таш тишә
Вода камень точит

Төпсез көймәгә утырырга
Сесть в дырявую лодку /Сесть в калошу

Теләмә озын җәй, телә җылы җәй
Не желай длинного лета, а желай тёплого

Ташыган диңгез дә кайта
И прилив моря завершается отливом

Тау булгач, чокыры булыр
Если есть гора, то будет и ущелье

Тау нихәтле биек булса да, кичүе булыр
Как ни высока гора – покорить можно

Томан төшә – җимешләр пешә
С туманом поспевает ягода

Сәвердәге явым – савып торган савым
Апрельский дождь воза золота стоит

Суны ут алмас, алтынны тут алмас
Вода не горит, а золото не ржавеет

Суның кадере чишмә корыгач беленә
Воду вспомнит как ручей иссохнет

Сиңа җил дә юк, яңгыр да юк

Тебе ни ветра, ни дождя

Сай елга шалтырап ага, тирән елга – тавышсыз
Чем река глубже, там она меньше шумит

Кара алтын – җир мае, аның белән ил байый
Нефть – черное золото, этим страна богатеет

Кар астыннан карга бугы да табылмый
Под снегом и вороньего помета не сыщешь

Кар матур да, аякны туңдыра
Снег красив, да ноги мёрзнут

Тыныч башым, тыныч колагым
Спокойна голова, спокойны и уши

Тыныч торасың килсә, кешене тыныч тот
Хочешь покоя, будь спокоен с людьми

Тырышкан табар, ташка казык кагар
Кто старается, тот найдёт и даже в камень гвоздь вобьёт

Тишекле таш җирдә ятмас
Дырявый камень на земле не лежит

Тамчы кечкенә генә булса да – таш тишә
Капля камень точит

Тамчы тама-тама таш тишә
Капля за каплей камень точит

Тамчы тамса да, диңгезгә су файда
Даже капля морской воды целебна

Тамчысыз диңгез булмый
Без капли моря не будет

# Время

Айлар да тигез түгел: берсе озын, берсе кыска
Даже месяцы не одинаковы – одни короче, другие – длиннее

Айның ундүртенче кичәсе кебек
Как 14 вечер месяца

Айның утыз көне бар, утыз төне бар
У месяца есть 30 дней и 30 ночей

Көннең киче иртәсеннән билгеле
Утро вечера мудренее

Атна кичнең килеше чәршәмбедән билгеле
Наступление конца недели чувствуется уже в среду

Атнада җиде җомга
Семь пятниц на неделе

Минутында тотмасаң, сәгатендә тоталмассың
Потерял минуту – потеряешь час

Атнасына алты ял
Шесть выходных на неделе

Көн көнгә охшап тумас, көн саен кояш булмас
День на день не приходится, каждый день солнца не бывает

Көн узсын, йон тузсын
Пусть день пройдёт, а шерсть сойдёт

Заман кош кебек: очып киткәч кире кайтмый
Время как птица: улетев – обратно не вернётся

Заманны бернинди җәүһәргә дә алмашып булмый
Время не обменяешь ни на какую драгоценность

Заманның ялына ябыш
Цени свободу времени

Заман үзе өйрәтә
Время само научит

Замана – көчленеке
Настоящее время – у сильного

Заманасына күрә дуңгызны җизни диярсең

Смотря какое время и свинью зятем назовёшь

Былтыргыны былтыратма
Не вороши прошлое

Былтырны шүрәле дә эзләп тапмаган
Прошлогоднего даже чёрт не сыщет

Бүген бар, иртәгә юк
Сегодня есть – завтра нет

Бүген белән көн бетми
День сегодня не заканчивается

Бүген болай, таңда әллә ничек
Сегодня так, а на рассвете уже по-другому

Бер көн артка калсаң, биш көн артка калырсың
Отставший на день, отстанет и на пять

Баш кашырга да вакыт юк
Даже затылок почесать некогда

Көн – эш өчен, төн – ял өчен
День для работы, ночь – для отдыха

Көндез таш ват, төнлә тыныч йокла
Днем ломай камни, а ночью спи спокойно

Көндез шырпы белән эзләп тапмассың
Днем с огнем не сыщешь

Вакыт акча түгел, югалтсаң таба алмассың
Время не деньги, потеряв – не найдһшь

Вакыт комны ташка, ташны комга әйләндерә
Время превращает песок в камень, а камень в песок

Вакытлы эш вакытында яхшы
Работа хороша вовремя

Вакытның дилбегәсе юк
У времени нет вожжей

Вакытың үтте – бәхетең китте
Время прошлом – счастье ушло

Безнең авылның көне бик озын, кечкенә авылның елы хәтле бар
День в нашей деревне равен году в чужой провинции

Артка калган болыт яумый үтәр
Запоздалая туча пройдёт без дождя

Алды барның арты бар, февральнең марты бар
У начала есть и конец, у февраля есть март

Узган гомер кире кайтмый сулар үргә акса да
Прожитая жизнь не вернётся, даже если вода будет течь обратно

Нух пәйгамбәр заманыннан
Со времён пророка Нуха / Со времён царя Гороха

Кырындагын кырык ел эзләгән
Сорок лет искал то, что было под боком

# Вера

Алладан курыкмаганнан курык
Остерегайся неверующего/безбожника

Чукын, улым, урысның күңеле булсын (вак-төяк гөнаһ кылу турында)
Крестись сынок, пусть христианин порадуется (про мелкие прегрешения)

Аллага да юк, муллага да юк
Ни Богу, ни мулле

Мулласы нинди – мәхәлләсе шундый
Каков поп – таков приход

Мулла песие кебек
Как у Христа за пазухой

Кунмыйм дигәнне караңгы кундырыр, адашмыйм дигәнне буран адаштырыр
Неверующему Фоме и свет померкнет, и вьюга запутает

Һәркем үзенә укына, һәркем үзенә чукына
Каждый молется о себе, каждый молется для себя

Яшең җитсә кырыкка, эшең китә шырыкка
Как исполнится сорок лет, все дела пойдут под гору

# Драгоценные металлы, камни

Алтын саз төбендә дә ялтырый
Золотои на дне болота блестит

Алтын туфракка аралаш чыгар
Золото и сквозь землю выйдет

Алтын чермәс, тимер тузмас
Золото не гниет, железо – не изнашивается

Дәрья төбендәге энҗедән тау башындагы таш артык
Жемчуг на дне земном ценнее камня на вершине горы

Алтын эчендә йөзү
Плавать в золоте

Алтынны коя белмәгән эретер, тирене или белмәгән черетер
Бережливый ювелир – приумножит, неумелый скорняк – уничтожит

Алтынчының бер органы – тимерченең мең органы.
У ювелира один орган, у кузнеца – тысяча

Өлешеңә төшкән көмешең
На долю выпало серебро

Тимерне кызуында сук
Куй железо пока горячо

Тимер булса, алтын да табыла
Будет железо, найдётся и золото

Тимер тоткан тилмермәс
Держащий железо не заржавеет

Тимере бар тилмермәс, каены бар кайгырмас
С железом не заржавеет, с березой не поседеет

Тимерне кызуында сук, балыкны уйнаганда тот
Куй железо пока горячо, лови рыбку пока клюёт

Калайны күпме шомартсаң да, көмеш булмас
Сколько железо не полируй, серебром не станет

Иске тимерне сакласаң, алтын булыр
Старое железо превратится в золото

Җәүһәр кадерен җәүһәрче белер

Ценность камня знает лишь ювелир

Гәүһәр кечкенә булса да, бәясе зур
Жемчуг невелик, да цена дорога

Бриллиант кара таштан чыгар
Бриллиант рождается из черного камня

Бакырны никадәр юсаң да, алтын булмас
Сколько медь не мой, золотом не станет

Бакырны күпме ешсаң да алтын булмас
Сколько медь не полируй, в золото не превратится

Алтынга пычрак ябышмый
Грязь к золоту не липнет

Алмазны алмаз белән кисәләр
Алмаз лишь алмазом режут

Алмазны балчык арасына ташласаң да, алмаз булыр
Алмаз даже в земле остаётся алмазом

Башны ташка орып булмый, орсаң да баш ярылыр
Лбом камень не разобьёшь, только голову расшибёшь

Тимерче кулында тимер балавыз кебек эрер
В руках кузнеца железо тает как воск

Таш астында көн күрер
Свет увидит под камнем

Таш астыннан чыккан
Вышел из-под камня

Таш белән атканга – аш белән ат
На камень метни в ответ едой / На зло отвечай добром

Таш чүлмәккә бәрелсә дә, чүлмәк ватыла; чүлмәк ташка бәрелсә дә, чүлмәк ватыла
Камень, столкнувшийся с горшком, сломает горшок, и горшок, столкнувшийся с камнем – разобьётся сам

Таш өстендә таш калмас
Камня на камне не останется

Ташка тамга салган
Оставил след на камне

Ташны таш белән ваталар, тимерне тимер белән игиләр

Камень ломают камнем, железо куют железом

Ташны ташлыйсы җиңел, күтәрәсе авыр
Камень легко выбросить, но сложно поднять

Кургашны көмеш дигәннәр, эрегән дә төшкән
Свинец назвали золотом, растаял / Не все золото, что блестит

Бакыр чыкмас җирдан, алтын эзләмә
Не ищи золота в земле и медной монеты не найдешь

# Родина

Ана суккан җир тамугта янмас
Земля, тронутая матерью, и в аду не сгорит

Көтү ташлаган малны бүре алыр, ил ташлаган ирне гүр алыр
Отбившееся от стада животное заберёт волк, отбившегося от страны человека заберет могила

Кеше илендә иш була алмыйсың
В чужом краю ровней не станешь

Ир егет үзе өчен туа, иле өчен үлә
Мужчина рождается для себя, а умирает за родину

Илдә булсаң – үлмәссең, илсез көн күрмәссең
На Родине не погибнешь, без Родины и света не увидишь

Илдә йөргән ил таныр, кырда йөргән җир таныр
Живущего на Родине – признает отчизна, живущего на чужбине признает лишь земля

Илдә чыпчык үлми
На Родине воробьи не гибнут

Алтын-көмеш яуган җирдән туган – үскән ил артык
Родина дороже золота

Иле барның теле бар
У кого есть родина, у того есть язык

Илен белмәгәннән игелек көтмә
От человека, не знающего своей родины, добра не жди

Иленнән аерылганның канаты каерылган
Отлучённый от родины – птица без крыльев

Иленә кайтуның ояты юк
Возвращение на родину – не стыд

Илеңне яу басса, йортыңны кар басар
Если родину настигнет враг, то дом запорошит снегом

Илнең күрке – тынычлык
Счастье родины – в покое

Илнең төтене дә тәмле
Даже дым на родине – услада

Илнең утына ян, бозына туң
За родину и в огонь, и в стужу

Илнең эше ирнең муенында, ирнең эше – илнең муенында
Отчизна на плечах мужа, а работа мужа – на плечах отчизны

Ватан барыннан да газиз
Отчизна дороже всего

Ватаны юк – җыры юк сандугач
Человек без родины – соловей без песни

Һәр чәчәкнең үз иле, һәр халыкның үз төсе
У каждого цветка своя страна, у каждого народа свой характер

Һәркемгә үз иле газиз
Каждому своя Родина дорога

Үз илем – алтын бишек, башка илнең төбе тишек
Родная страна – золотая колыбель, чужая – дырявое корыто

Үз иләндә йөри җиңен салып, чит илдә – мескен, гарип
На чужбине и сладкое в горчицу, а на Родине и хрен за леденец

Үз илең – гөлстан, кеше иле – гүрстан
Своя сторона по шерсти гладит, чужая – насупротив

Үз илеңдә карлыгач булсаң да, чит илдә карга буласың
Даже если ты ласточка на родине, на чужбине – будешь вороной

Якасы юк тун булмас, законы юк ил булмас
Нет тулупа без ворота, нет страны без закона

Чит илдә бай булганчы, үз илеңдә гидай бул
Будь бедным в родном краю, чем богатым – в чужом

Читне макта – илеңдә тор
Заграницу хвали, но живи на Родине

Халыкның бер йорты бар, ул да булса – туган ил
У народа есть один дом, то бишь Родина

Туган илдән туйган юк
Своя земля и в горести мила / Своя земля не надоест

Туган илең – туган анаң, чит ил – үги ана
Родная земля – мать, чужая – мачеха

Туган илнең җире – җәннәт, суы – ширбәт

Родная земля – рай, а вода – нектар

Туган җирдән туйган җир яхшы
Страна, где ты сыт, лучше той, где родился

Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил
Чужой край мил, да родина милее

Ил өстеннән берәр җеп – бер ятимгә күлмәклек
Государственная нить – платье сироте

Ил өчен яшәмәгән кеше – үзе өчен дә яшәми
Не живущий для родины и для себя не живёт

Ил аткан таш еракка барып төшәр
Камень, брошенный с родины, летит далеко

Ил бай булса, ярлылыгың сизелмәс
Если государство богатое – бедность не ощутится

Ил белән киселгән бармактан кан чыкмый
Рана, нанесенная страной, не кровоточит

Ил күргәнне күрербез
Увидим то, что видела родина

Ил теләр аманлык, дошман теләр яманлык
Родина желает благополучие, враг – неудачу

Ил төкерсә, күл булыр
Где плюнет родина – будет озеро

Ил эче – алтын бишек
Сердце родины – золотая колыбель

Ил өстендә чыпчык үлми
Птица не умирает над своей родиной

# Смерть

Үлгән артыннан үлеп булмый
Вслед за умершим умереть не получится

Үлгән сыер сөтле була
У мертвой коровы много молока

Исән чакта сыйламаган үлгәннән соң еламый
Не жалующий в здравиии после смерти страдать не будет

Дүрт ягың – кыйбла
Иди на все четыре стороны

Бер аягы түрдә, икенчесе – гүрдә
Одной ногой на пороге, другой – в могиле

Берәү үлми, берәү көн күрми
Один не может умереть, второй – света белого увидеть

Үлгәннән соң тәубә юк
После смерти за грехи не покаешься

Әҗәлдән дару юк
От смертинет лекарства

Төн үткәнче җан чыккан
Во время ночи душа вышла

Тереләрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел
Знай ценность живых и могилы ушедших

Күрәчәгең булса, күркә талап үтерер
Если суждено смерть настанет от индейки

Күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый
Пока своё не проживёшь – в могилу не войдёшь

Каберең якын булмасын (начар кеше белән)
Пусть могила не будет рядом (с плохим человеком)

Йә тәхет, йә ләхет
Или трон или могила

Дөнья эшен ахирәткә калдырма
Людские дела на загробную жизнь не оставляй

Бөкрене кабер генә төзәтә

Горбатого только могила исправит

Берәү үлә, берәү туа
Один умирает, другой рождается

# Добро, зло

Яхшы булса – бидән, яман булса – колдан
Добро – от боярина, зло – от раба

Яхшы булсаң сөярләр, яман булсаң төярләр
Хорошего – любят, плохого – колотят

Яхшы суны ерак түкмиләр
Хорошую воду далеко не выливают

Яхшылык ташны да эретә
Добро и камень растопит

Яхшылык күрәсең килсә, яхшылык эшлә
Хочешь получать добро – делай добро

Усал булсаң асарлар, юаш булсаң басарлар
Будешь злым – повесят, а будешь мягким – раздавят

Таш белән органга аш белән ор
Отвечай добром на зло

Надан кеше сукырдан яман
Глупый человек хуже слепого

# Одиночество

Ялгызлык таштан да каты
Одиночество и камня твёрже

Ялгызлык яман юлдаштан хәерлерәктер
Одиночество лучше плохого товарища

Ялгызлык ят илдә беленер
Одиночество ощущается в чужом краю

Ялгызның көче бетәр, эше бетмәс
Силы одинокого покинут, работа – нет

Ялгыз кеше – ялсыз кеше
Одинокий человек – человек без отдыха

Ялгыз кеше барлы булса да зарлы
Одинокий человек хоть и богат, но грустен

Ялгызга юл озак
Одинокому и дорога длинна

Хатыны юкның якыны юк
У кого нет жены, у того нет близкого (тот одинок)

Берүзең тау күчерә алмыйсың
Один горы не сдвинешь

Ялгыз каенга кош кунмас
На одинокую берёзу и птица не сядет

Үз казанында кайнарга
Вариться в собственном соку

Үзең генә җырлаганчы, икәүләшеп тын утыру рәхат
Молчание вдвоём дороже пения в одиночку

Сайланган сазга баткан
Перебирающий застрянет в болоте

Парлы булсаң – гөл сибәрләр йөзеңә; ярлы булсаң – көл сибәрләр күзеңә
Если у тебя есть пара – будут кидать цветы, а если ты беден – пепел

Кимчелексез дус эзләгән – ялгыз калган
Ищущий друга без изъяна – останется одинок/ Поиск идеала приведёт к одиночеству

Ирсез хатын – йөгенсез ат

Незамужняя женщина – необузданная лошадь

# Время года

Ябага тайны хурлама – язга чыкса ат булыр
Не ругай линяющего жеребца – по весне станет лошадью

Явым теләсәң, давылына да чыда
Ждешь дождя, стерпи и ураган

Яз берәүне аздырыр, берәүне малдан яздырыр
Весна – одного одарит, а другого – оставет без скотины

Яз кайгысын кыш кайгырт, кыш кайгысын яз кайгырт
О весенних заботах думай зимой, о зимних – весной

Яз сөрсәң, көз урырсың
Вспашешь весной – пожнёшь осенью

Яз уңмаган көз уңмас
То, что не поспело весной, и осенью плодовне даст

Кавәс тумый кыш булмый, җәүза тумый җәй булмый
Не родившись стрельцу не быть зиме, не родившись близнецам – лету

Җәй алмаска, кыш бирмәскә
Летом не брать, зимой не давать

Җәй бар, кыш бар, ашыгып ни эш бар
Лето есть, зима есть, куда спешить

Җәй көнне бияләй, кыш көнне майка сатып ал
Покупай летом варежки, а зимой майку

Җәй көнне йоклама, кыш көнне өлгерерсең
Не спи летом, отоспишься зимой

Җәй көнне чанаңны, кыш көнне арбаңны әзерләп куй
Готовь сани с лета, а телегу зимой

Җәй җәйләдем, кыш кышладым, мич башыннан төшмәдем
Лето пропел, зиму перезимовал, но с печи не слезал

Җәйгә чыккан җан үлмәс
Дожившая до лета душа не умрёт (будет здорова)

Җәйгә чыксаң кышны уйла, кышка керсәң җәйне уйла
Летом задумайся о зиме, а зимой о лете

Җәй эшләсәң, кыш ашарсың

Летом поработаешь – зимой поешь

Бер кырпак белән кыш булмас
От одной пороши (с первого снега) зима не начинается

Бер карлыгач белән яз булмый
Одна ласточка весны не делает

Бер елда ике яз булмый
Две весны в один год не наступают

Яз җитсә чебенгә дә җан керә
Весной даже мошка набирается силы

Язгы көн ел туйдыра
Один весенний день год кормит

Язгы хезмәт – көзге хөрмәт
Весенний труд – осенний почёт / Весенний труд – осенние плоды

Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы
Для глаз отрада весна, а для рта – осень

Иртән уңмаган һич уңмас
Не сделанное утром, вечером и подавно не доделается

Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш
Весенне богатство – солнце, осеннее богатство – урожай

Язның пычрагы да ямьле була
У весны даже грязь живописна

Октябрь ни арба, ни чана
Октябрь – ни телега, ни сани

Октябрь – кара бия, ноябрь – ала бия
Куда октябрь поведет, туда ноябрь и свернет

Көзге көн ул бала кебек: әле көлә, әле җылый
Осенний день как дитё: то плачет, то смеётся

Көзге көн – арткы акыл, язгы көн – ярты акыл
Осенний день – поздний ум, весенний день – половина ума
Көзге көн – кияү акылы, язгы көн – яшь килен йөзе
Осенний день – разум зятя, весенний день – молодое лицо невесты
Көзге көннән язгы төн яхшы
Весенняя ночь лучше осеннего дня

Көзге юлга кием ал, язгы юлга азык ал

На осеннюю дорогу запасайся одеждой, а на весеннюю – едой
Кыш бетте дип тун сатма, янә кыш бар
Не продавай тулуп по окончании зимы – настанет новая

Кыш булганын колагы туңганнан белгән
Зиму узнал по замёрзшим ушам

Кыш көне кулыннан кар ала алмассың
У зимы снега не выпросишь

Кыш рәхәт чанага, җәй рәхәт арбага
Зима хороша для саней, а лето – для телеги

Кыш – кыямәт, яз – җәннәт
Зима – день расчета, лето – рай

Кыш – үги ана, яз – үз ана
Зима – мачеха, а весна – родная мать

Кышка каршы тиен дә запас җыя
К зиме даже белка запасается

Кышкы көннең җылынуына ышанма
Зимой на потепление не надейся

Кышкы көннәр җәйне әйтер, җәйге көннәр җайны әйтер
Зимние дни зовут лето, летние дни – покой

Кышның күзе караңгы: ни кисәң дә ярый
Зимние глаза – потёмки: что бы ни надел подойдёт

Кара көзнең кары ятмас
У чёрной осени не бывает снега

## День, ночь

Төн кара булган саен, йолдыз яктырак янар
Чем ночь темней, тем ярче звезды

Төн чыкканчы җөн чыккан
Утро вечера мудренее, трава соломы зеленее

Төннең тынычлыгы – көннең куанычы
Ночной покой – дневная радость

Таң белән атып, көн белән батып
От заката до рассвета

Таңы атмаган төн булмас
Без рассвета и ночь не наступит

Төсең кара булса да, күңелең ак булсын
Даже если настроение плохо, пусть душа будет светла

Кешегә калган көн – таң атмаган төн
Оставленный на другого день – словно ночь без рассвета

Иртә торган – эшеннән куанган
Утро вечера мудренее / Утренная работа спорится

Иртә торганга ике өлеш
Для вставшего спозаранку – две порции

Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас
Что не поспело утром – и к вечеру не поспеет, что не поспело к вечеру – пропало

Иртә чыксаң – алдыңнан көн чыга, кич чыксаң – алдыңа төн чыга
Выйдешь спозаранку – встретишь день, выйдешь вечером – встретишь ночь

Баткан көннең аткан таңы бар
За закатом следует рассвет

Кич булмыйча бүгенге көнне мактама
Не хвали день покуда вечер не настал

Көн белән төн бер булмый
День ночи не равен

Иртәгәгә ышанып, бүгенге көнеңне кулдан ычкындырма
Надеясь на завтра, не упускай из рук сегодня

Иртәгәсе өчен ишәк кайгырган

По поводу завтра переживает лишь осёл

# Дорога

Юлдан алда юлчы, өйдән алда күрше белеш
Перед дорогой узнай путника, а до дома – узнай соседа

Юлчыга янчык та авыр
Путнику и кошель втягость

Юрганыңа күрә аягыңны суз
По одеялу и ноги протягивают

Юлдашын ташлаган – юлда калыр
Бросивший попутчика – останется в дороге

Урау булса да юл яхшы, шадра булса да кыз яхшы
Дорога хороша, хоть и обходная; девка хороша, хотя и рябая

# Жизненные ситуации

Үз хәсрәтем үземә җиткән
И своего горя достаточно

Ата алмаган җәя сайлар
Кто не может выстрелить, тот выбирает лук

Аткан ук кире кайтмас
Выпущенная стрела обратно не вернётся

Ашыккан су диңгезгә җитмәс
Торопливый ручей моря не достигнет

Аҗаган-кайнаган урын
Самое пекло

Авырлык күрмәгән рәхәтне белми
Не вкусивгоря, не узнаешь и радости

Авырткан тешкә тел тия
Язык всегда больной зубзадевает

Агач атка атландыру
Посадить в галошу

Агымга каршы йөзеп булмый
Против течения не поплывёшь

Адым-адым – юл булыр, тамчы-тамчы – күл булыр
Шаг за шагом будет путь, капля за каплей – озеро

Аерылган ил азар, кушылган ил – узар
Развалившаяся страна отстанет, воссоединившаяся – опередит

Адашкан кешедән юл сорама
Не спрашивай дорогу у заблудившегося

Аз булсын, яхшы булсын
Мал золотник, да дорог

Азагын күрсәтмәсәң, башын башлама
Не стращай началом, покажи конец

Аздан күп була, күптән юк була
Из малого получится многое, а из многого – ничего

Оясында ни булса, очкынында шул булыр

Что в гнезде, то и на себе

Начар арба юл боза, начар түрә ил боза
Плохая телега портит дорогу, плохой чиновник – портит страну

Начарны күрмәс борын, яхшының кадере юк
Плохого нос не узрел, а увидеть хорошее никто не созрел

Колакка киртеп куярга
Зарубить себе на носу / букв. “на ушах”

Кискән ипи кире ябышмый
Отрезанный ломоть обратно не приклеишь

Йокы тамак туйдырмый
Одним сном сытне будешь

Искега тимә, исең китәр
Кто старое помянет, тому глаз вон

Запас эчне тишми
Запас карман не тянет

Вактан эре җыела
Из мелкого собирается крупное

Буккатимәсәң ис чыкмый
Не трогай грязь, не испачкаешься

Беткә үч итеп тунны утка якмыйлар
На зло вшам шубы не сжигают

Авылыңда ни барны башка авылдан сора, өеңдә ни барны күршедән сора
Новости своей деревни узнаешь в соседней, новости своего дома узнаешь от соседей

Авызыңа салганны йота бел
Не откусывай больше того, что ты в состоянии проглотить

Аракы керсә, оят качар
Вино приходит – стыд уходит

Ашыккан ашка пешкән
Поспешишь – людей насмешишь

Авыр басканчы, җиңел калкадыр
Лёгок на подъём / Лёгкость наступает перед трудностью

Иелгән башны кылыч кисми
Топор склонённую головуне рубит

Изге урын буш булмас
Свято место пусто не бывает

Ике арада битараф
Нейтральный между двумя

Ике тамчы су кебек
Как две капли воды

Авылны макта, шәһәрдә тор
Хвали деревню, живи в городе

Агач күрке яфрак, әдам күрне – чүпрәк
Красота дерева спрятана листьях, человека – в одежде

Ач ирнең ачуы яман
Голодный муж – злой

Ачу йоту – тау йоту
Затаить обиду словногору проглотить

Андый бишкойрыкның (җилбәзәк, җиңел акыллы) бер койрыгын да тоталмыйсың
Такого пятихвостого и за один хвост не удержишь

Авызыңда кан булса да кеше алдында төкермә
Даже если рот полон крови – не стоит плевать перед людьми

Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән кермәс
То, что не вошло с материнским молоком, с коровьим уже не войдет

Ачык ишек, якты чырай
Открытые двери, приветливое лицо / Нет двери, которую бы не открыла любезность

Бал тәмле дә, корт чага
Мёд сладок, да пчёлы жалят

Балтасы суга төшкәндәй
Как в воду опущённый

Баскан җиреннән ут чыга
Где след, там и огонь

Без капчыкта ятмас
Шило в мешке не утаишь

Бияләй эченнән йодрык күрсәтмә
Кулак в рукавице не показывают

Башың карт булса да, йөрәген яшь булсын
Пусть сердце остаётся молодым даже с седой головой

Бүгенге ачуны иртәгәгә саклама
Не храни обиду до завтра

Бүген миңа, иртәгәгә сиңа
Сегодня – мне, а на завтра тебе

Баш сау булса, башка бүрек тә табылыр
Была бы голова цела, ушанка найдётся

Беркемнең дә башы ике түгел
Ни одна шеядве головы не удержит

Биргәннең битенә карама
Дающему в лицо не смотрят

Бүләк – атның тешенә карамыйлар
Дарёному коню в зубы не смотрят

Бата торган – еланга да тотына
Утопающий и за змею схватится

Батканга яңгыр куркыныч түгел
Утопающему дождь не страшен

Батсаң – таза суга бат
Если и тонешь, то делай это в чистой воде

Башы барның соңы бар, әүвәле барның ахыры бар
У начала есть конец, у почина есть венец

Башыңа төшсә башмакчы, булырсыңторучы
Упадёт башмак на голову – станешь башмачником

Башыңа төшсә, түмгәккә дә сәлам бирерсең
Упадёт на голову, и пню начнёшь кланяться

Бал-май эчендә йөзәргә
Как сыр в масле кататься

Бай – саңгырау, түрә – сукыр
Богач – глухой, вождь – слепой

Бай башына кол җитәр
И на голову богачахватит рабов

Байдан батрак артмый

Батраков для богача много не бывает

Белгән җирдә баш кадерле, белмәгән җирдә тун кадерле
В знакомом месте – ценность самого человека, в чужом – его кафтан ценен

Батыр ярасыз булмас, ярасы дәвасыз булмас
Богатырь не бывает без ран, раны не бывают без исцеления

Бер елны бүдәнә симерсә, икенче елны тартар симерә
Если в нынешнем году потолстел перепел, то в следующем – дергач

Бикә бизәнгәнче туй бетә
Пока дама нарядится – свадьба закончится

Бу чакта бияләй эчендә бармак кыймылдатканны беләләр
В такие моменты и шевеление пальцев в рукавицах заметно

Бугын бизмәнгә сала
Всю грязь кладёт на весы

Баш тубал булды
Голова как рой пчёл

Баскан да каткан
Встал как истукан

Бир миңа да мин – синңа
Рука руку моет

Бит күрке – күз, тел күрке – сүз
Красота лица – глаза, а языка в словах

Бишкә урын табыла, бергә урын табылмый
Пятерым хватит места, а одному – нет

Боермак сездән, йөгермәк бездән
Командование – с вас, беготня – с нас

Буш башлар туры баса, тулылары иелә
Пустые головы стоят прямо, умные – склоняются

Биткә бияләй каплап
Скрыться за варежкой

Бал ачымас, кыз картаймас
Мёд не застоится, девица не состарится

Бер күктә ике кояш була алмый
Двух солнц на одном небе не бывает

Былтыр яуган карны быел эзләү ни файда
Прошлогодный снег искать сейчас бесполезно

Буклы чабата да кайчакта кирәк була
И худой (грязный) лапоть порой пригождается

Барына канәгать бул, югына сабыр ит
Будь благодарен за все, что имеешь, и принимай терпеливо то, чего у тебя нет

Булыр-булмаска ышанма, кулыңдагыдан аерылма
Не верь тому, чего пока нет, не расставайся с тем, что в руках

Бай булсаң илең сыяр, сау булсаң ирең сыяр
Богатству сулит слава, здоровью – любовь

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз
Доброму молодцу и семидесяти ремесел мало

Гаеп мулла кызында да була
Грешной бывает и дочь попа

Гел-гел ак күмәч белән майлы ботка да туйдыра
Постоянные белый хлеб и каша с маслом – надоедают

Гомер уза, күлмәк туза
Жизнь проходит, а платье ветшает

Егетлек кадерен карт белер
Цену молодостизнает лишь старик

Иске яңаны саклый
Старое бережёт новое

Җиңелне эзләгән авырга каба
Тот, кто ищет лёгкое, натыкается на тяжёлое / Бесплатный сыр только в мышеловке

Җиңелне җил күтәрер, авыр урынында калыр
Лёгкое поднимает ветер, а тяжёлое остаётся на месте

Еракка яшерсәң, якыннан алырсың
Спрятав далеко – найдёшь рядом

Еракта – кешнәшер, якында – тешләшер
Вдалеке – ржёт, вблизи – кусается

Ерактагы чап була, киләкилә чак була
Дальняя слава со временем меркнет

Ерактан арба белән китергәнче, якыннан капчык белән китер
Чем на телеге издалека, неси вмешке вблизи

Еракка яшерсәң, якыннан алырсың
Спрятав далеко, возьмешь вблизи

Ерактагы кояш нык кыздыра
Дальнее солнце греет сильно

Җан биргәндә юнь биргән
Отдавая душу, нашёл путь

Җил исми, яфрак селкенми
Без дуновения ветра и листик не шелохнётся

Җиде кат үлчә, бер кат кис
Семь раз отмерь, один раз отрежь

Җан тартмаса, кан тарта
Не душа, так кровь тянет

Җан җәннәт тели – гөнаһ җибәрми
Душа желает рая, но грех не отпускает

Җете кызыл тиз уңа
Ярко-красный быстро линяет

Җиде кат җир астына керсә дә эзләп табар
Найдет даже то, что спрятано за семью печатями

Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны тындырмый
Жар костей не ломит, холод душе не даёт покоя

Җылы тәнеңдә тузсын
Пусть износится на тёплом теле

Җәяүлегә янчык авыр
Пешему и кошель втягость

Заманың ничек булса, бүркеңне шулай ки
Носи головной убор по погоде

Зур күтәреп бәләкәй суккан
Мал да удал

Зур нәрсәне кечкенә белән үлчиләр
Большое меряют малым

Ике куянның (көймәнең) койрыгын тотарга

За двумя зайцами погонишься, ни одного не поймаешь

Кара товар кыйммәтле була
Чёрный товар – ценный

Кул кулны юа, ике кул битне юа
Рука руку моет, а две руки лицо моют

Кысыр хасрәттан башыңны кайгыга салма
Пустые печали не стоят переживаний

Көчләнеп яр булып булмый
Насильно опорой не стать

Кемнең кулында – шуның авызында
У кого в руках, у того и во рту

Кеше ризыгын кеше ашамый
Предначертанное человеку никто не отберёт

Кешенеңкем икәнлеге маңгаена язылмаган
У человека на лбу не написано – кто он

Көче җиткәнгә – көчектәй
Сильный брюхом – слабый духом

Көчең барда эшлә, тешең барда тешлә
Силы есть – работай, зубы есть – грызи

Күп яшәгән ни белгән, күпне күргән шул белгән
Мудр не тот, кто долго прожил, а тот, кто многое поведал

Кара халык – кара сарык
Темнокожий народ – чёрная овечка

Карга күзен карга чукымый
Ворон ворону глаза не выклюет / Чёрные глаза в снегу не спрячешь

Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр
Кто не знает, что такое свет, тот зажжёт лучину и днём

Көн күрмәк кеше белән
Человек живет с людьми

Күз курка – кул йолка
Глаза боятся – руки делают

Күз күрә берне, күңел – меңне
Глаза видят одно, а сердце – тысячу

Кызуы да пешерә, суыгы да пешерә
И горяее печёт, и холодное печёт

Кызыл кар яуганда
Когда пойдёт красный снег

Кисеп ташлаган тырнагына да тормый
И в подмётки не годится / Отрезанного ногтя не стоит

Кемнең кулында, шуның авызында
Своя рука владыка /У кого в руках, у того и в зубах

Көтүче нинди, көтүе дә шундый
Каков пастух, такого и стадо

Сыйлаганда су эч
Пей воду, если угощают

Кыз картаймый, бал череми
Девушка не стареет, а мёд не портится

Кала хәлен беләсең килсә, салага бар
Столичные новости узнаешь в селе

Калын сандал чүкечтән курыкмас
Мощная наковальня молота не боится

Каләм изгегә тартыр
Карандаш тянет к искусству

Кылыч күтәргән – кылычтан үтәр
Поднявший мечь – сам поранится

Кеше йортында йөреп солтан булганчы, үз йортыңда йөреп олтан бул
Чем в чужом доме быть султаном, будь подошвой в своём

Кеше күңеле пыяла, нык кагылсаң уала
Чужая душа – хрусталь, чуть тронешь – разобьётся

Кая барсаң да кара, сакалың артыңнан калмый
Куда бы не пошёл, твоя борода идёт следом

Кая барсаң да, бер кояш
Куда бы ни пошёл, солнце то же

Кем арбасына утырасың, шуның җырын җырларсың
На чью телегу сядешь, те песни и будешь петь

Кара болыт булып йөрү
Ходить как чёрная туча

Кара ипине җиксенсәң, кара көнгә калырсың
Будешь сторониться чёрного хлеба – окажешься в чёрных днях

Керереңнән алда, чыгарыңны уйла
Перед тем как зайти, подумай, как будешь выходить

Кечкенә булса да, эче төш кенә
Мал золотник, да дорог

Кечкенә дошман зур пошман китерер
Маленький враг принесёт много бед

Каракның бүреге яна
На воре и шапка горит

Колак итен ашарга
Прожужжать уши

Күбенә түзгәнне, әзенә дә түзәрсең
Вытерпев многое, и малое переживёшь

Карама беләкккә – кара йөрәккә
Гляди не на руки, а на сердце

Караңгы төннән соң якты көн килә
Даже после самой тёмной ночи наступает рассвет

Караңгыда күз кысканы беленми
В темноте подмигиваний не видно

Ак белән караны аера белмәү
Не уметь отличить чёрное от белого

Ак булмаса да, пакь булсын
Даже если не белое, так хотя бы чистое

Ак нәрсә кер күтәрми
Белая вещь не притягивает грязь

Акка кара белән язылган
Написано чёрным по белому

Акка кара тиз йога
К белому чёрное быстро пристаёт

Аккан су кире кайтмас

Течение реки не повернуть вспять

Аккан суга монтар юк
Текущей воде преград нет

Акны кара дип әйтү
Принимать белое за чёрное

Акны күп таушалдырсаң, карага әйләнер
Если белое долго мусолить, оно становится чёрным

Аксөяк эш сөймәс
Белая кость не любит работу

Алга бар – артыңа кара
Двигаясь вперёд, оглядывайся назад

Алда барма, артта калма
Не беги вперёд, но и в конце не плетись

Алдыңа бер карасаң, артыңа биш кара
Посмотри вперёд один раз, а назад – пять

Алдыңа кара – кая барганыңны белерсең, артыңа кара – каян чыкканыңны белерсең
Посмотришь вперёд – увидишь направление, взглянешь назад – увидишь пройденный путь

Алдыңда – ялтырый, артыңда – шалтырый
Спереди блестит, сзади бренчит

Андый гына хан кызында да була
Такое и у царской дочери бывает

Аннан игелек күрсәң, Алладан каза күрерсең
Получая от него доброту, от Бога получишь беду

Аның күле тирән
Его озеро глубокое

Аптыраган үрдәк арты белән чума ди
Удивлhнная утка ныряет хвостом

Арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит
Сломанная телега – к дровам, смерть быка – к мясу

Артында патшаны да сүгәләр
За спиной ругают даже царя

Асыл нәрсә зур булмый

Истинные вещи большими не бывают

Үтмәс пычак та кул кисә
Даже тупойнож может поранить руку

Үзе егылган еламас
Упавший по своей вине не заплачет

Үз урынын белмәгән, урынсыз калыр
Не знающий своего места – останется без него

Үзе юкның күзе юк
На нет и суда нет

Үзен зур тоткан түрәнең, соңы хур булыр
Высоко взлетел, да низко падёт

Төрмә бик таза да, берәү дә кереп ятарга теләми
Тюрьма – добротная, но никто не желает там оказаться

Агачның асылын корт ашар
Самое ценное в дереве поедают жуки

Шайтан таягына кырау тими
Чертову палку заморозки не берут

Түбәнгә карап шөкер ит, югарыга карап фикер ит
Смотри вниз и благодари, сморти вверх и размышляй

Түбәң күктә булса да, аягың җирдә булсын
Даже если голова на небесах, ноги пусть будут на земле

Тотылмаган – карак түгел
Не пойман – не вор

Таяк ике башлы
Палка о двух концах

Син күр дә мин күр!
В мгновение ока!

Тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк
Умеешь желать – желание, не умеешь – бремя

Тырнак астыннан кер эзләмә
Не ищи грязь под ногтями

Тилегә юл куй
Дай дорогу дураку

Симез суйның гөмере кыска
Жизнь толстой овцы коротка

Сукыр күп күрер, аксак күп йорер
Слепой много видит, хромой много ходит

Соранучы күп, бирүче генә юк
Просящих много, только дающих – нет

Сөттән ак, судан пакь
Белее молока, прозрачнее воды

Сүтек ертыктан көлгән ди
Прореха над прорезью смеётся

Сәбәпсез яфрак та селкенми
Без причины и лист не шелохнётся

Суган суы суырып (бушка диярлек эшләү, шул сәбәпле бик ярлы яшәү турында)
Болота исходил, а рыбы не наловил / Жить впроголодь / Пить луковую воду

Сугыш беткәч, батыр күбәя
После боя все кулаками машут

Сугыш корбансыз булмый
Войны без потерь не бывает

Сугышка барып чукмарын оныткан
В бою булаву потерял

Сугышка чукмарсыз бармыйлар
В бой без палицы не ходят

Суда балык адашмас
Рыбка в воде не потеряется

Суда көймә эзе беленми
След лодки на реке не остаётся / Не заметен

Су чокыр җиргә җыелыр
Вода собирается в яме

Су язып май төшмәс
Масло с водой не смешаешь

Син дә мулла, мин дә мулла – атка печән кем сала?
И ты поп, и я поп, а кто коровам сено даёт?

«Сакланганны саклармын», – дигән ходай
Бережёного Бог бережёт

Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың.
Не потопаешь, не полопаешь

Сабыр иткән – морадына җиткән
Терпение приносит спасение

Сабыр төбе – сары алтын
На дне терпения скрыто золото

Сүзе хакны, йөзе ак
Там, где правда, там и светлый лик

Соравына күрә җавабы
Какой вопрос – такой ответ/ Какова музыка, таков и танец

Патша талап ала, хәерче теләнеп ала
Царь грабеңом берёт, а нищий – попрошайничеством

Патшадан курыкма, губернаторыңнан курык
Бойся не царя, а губернатора

Патшаң сукыр булса, бер күзеңне кысып үт
Если твой царь слеп, пройди закрыв один глаз

Олы кеше – солы төше
Старый человек – овсяная шелуха

Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне
Уважая старших, будешь уважаем сам

Олы башыңны кече итеп йөрмә
Старую голову не выставляй как молодую

Озын янында кыска беленер
Низкий выделяется рядом с высоким

Ни чәчсәң, шуны урырсың
Что посеешь, то и пожнёшь

Ни ылтара, ни пылтара – калган ике уртада
Ни туда, ни сюда – остался промеж двух (на перепутье)

Миннән киткәнче, иясенә җиткәнче
Пока от меня уйдёт и пока до хозяина дойдёт

Миңа дисә: ни эссе түгел, ни суык түгел

Мне ни горячо, ни холодного от этого

Мондый көндә яхшы кешенең эте дә йөрмәс
Хороший хозяин и собаку в такую погоду на улицу не выгонит

Морҗаң кыек булса да, төтене туры чыксын
Даже если труба кривая, дым пусть прямо идёт

Муенга тагылган таш булдың
Лёг камнем на шею

Маңгаена язылган
На лбу написано

Мәчегә уен, тычканга кыен
Для кота игра, для мышки – сложности

Курыксан – эшләмә, эшләсәң – куркма
Боишься – не берись, взялся – не бойся

Күз күрә берне, күңел – меңне
Глаза видят одно, душа – многое

Карама беләккә – кара йөрәккә
Гляди не на руки, а на сердце

Коега таш ташлау җиңел, алуы гына авыр
Легкобросать камни в колодец, а вот достать – сложно

Коега төкермә, кайтып су эчәрсең
Не плюй в колодец – и тебе из него пить придётся

Комнан аркан ишү
Строить замки из песка

Куеныңда таш саклау
Хранить камни за пазухой

Корал эшләр, ир мактаныр
Оружие сделает, а муж похвастается

Кешегә кое казысаң, үзең буе казы
Роешь чужому колодец – делай это под свой рост

Кешене тыңла, үзеңнекен эшлә
Слушай других, но делай по-своему

Кыскалыкта – осталык
Краткость – сестра таланта

Олы йортка ни кирәк – кечесенә шул кирәк
Что нужно старому дому, то нужно и молодому

Ничә чәйнасәң дә бер балык башы
Сколько бы нижевал, все – голова одной рыбы

Керереңнен элек чыгарыңны уйла
Прежде, чем войти, думай, как будешь оттуда выходить

Кызыл кар яугач
После дождичка в четверг

Кеше кубызына биергә
Плясать под чужую дудку

Кашьяк шалтырамый тормый
Посуда не лежит без шума

Кирәк ташның ауры юк
Своя ноша не тянет

Көнбагыш – эш калдыргыч, аракы – ыштан салдыргыч
Семечки – друг безделья, водка – друг бедности

Күзгә төртсәң күренмәслек
Ни зги не видно

Карт хәтере – тишек иләк
Память старика – обветшалое сито

Күпне көткән, аздан коры калыр
Много хочешь – мало получишь

Курыкканга куш күренә
У страха глаза велики

Курыкканны эт абалый
Пугливого и собака не пропускает

Кыз мактала эш белән, түгел энҗе теш белән
Девица славится работой, а не жемчужными зубами (улыбкой)

Бергә чакта талашыр, аерылгачтын ялашыр
Что имеем не храним, а потерявши плачем

Бердә түгел, илдә көч
В единении – сила

Берегүдә – бәрәкәт, аерылуда – һәлакәт
Счастье в единстве, а в разлуке – погибель

Беренче коймак төерле була
Первый блин комом

Берлек кайда – көч шунда
Сила в единстве

Берне сугып икегә тию
Убить двух зайцев одним выстрелом

Түбәсе күккә тию
Быть на седьмом небе

Бәхет тәхеттә түгел
Счастье не во власти

Без күрәсен кем күрсен
Предначаретанное нам – чужой не увидит

Ике уйла, бер эшлә
Сделай один раз, но подумай дважды

Икәү белгәнне ил белә
То, что знают двое – узнает весь мир

Яшь чак – дәртле чак
Молодость – сила

Бер картлыкта – бер яшьлектә
И в старости, и в молодости

Бер рәхмәт мең бәләдән коткарыр
Одно спасибо спасёт от тысячи напастей

Күп кызлы йортта су булмас
В доме, в котором много девочек, воды не бывает

Исереккә диңгез тубыктан
Пьяному и море по клено

Көлгән түрәдән ерак кач
Держись подальше от улыбающегося начальника

Иске яңага урын бирер
Старое уступит место новому

Иске яңаны саклый

Старое хранит новое

Искегә тисәң, исең китәр
Кто старое помянет – тому глаз вон

Искесез яңа булмас, ямансыз яхшы булмас
Без старого не будет нового, без плохого – не будет хорошего

Искә алмаган түмгәк чана аудара
Забытый чурбан сани перевернёт

Дөя дә бүләк, төймә дә бүләк
И верблюд подарок, и пуговка

Дөньяныкы дөньялыкка калсын
Жизненное пусть останется при жизни

Дөнья күләсә – әйләнә дә бер баса
Земля круглая, прокрутится и все встанет по местам

# Гостеприимство

Кул кулны юа, ике кул битне юа
Рука руку моет, две руки лицо моют

Кунак – хуҗаның ишәге
Гость – ишак хозяина

Кунак ашы – кара-каршы / Бәйрәм ашы – кара-каршы
Угощение гостям – взаимно / Долг платежом красен

Кунак булсаң, тыйнак бул
Будь гостем, но будь сдержанным

Кунакта яхшы, өйдә биш битәр
В гостях хорошо, но дома гораздо лучше

Кунаклы йорт – хөрмәтле йорт
Дом с гостями – уважаемый дом

Кунакта яхшы, өйдә яхшырак
В гостях хорошо, а дома лучше

Көтеп алган кунак кадерле була
Долгожданный дождь – дорог

Сыйлаганда су эч
Пей воду, когда угощают

Сыйлы кунак – сыенда, сые беткәч – өендә
Гость с гостинцами в гостях, а как закончатся – дома

Сыйлы көнең – сыерлы көнең
Сытый день настаёт с коровой